Казан (Идел буе) федераль университеты

**Р.М. Галиева, Л.Р.Сабирова**

# Фәнни язма эшләр, практика.
# Татар журналистикасы бүлеге студентлары өчен хисап тәртибе

**Казан**

**2014**

**УДК 070**

Казан (Идел буе) федераль университеты Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының укыту-методик комиссиясе (беркетмә № 7, 20.05.2014) һәм татар журналистикасы кафедрасы (беркетмә №11, 13.05.2014) утырышларының карары нигезендә басыла

*Фәнни редактор:*

филология фәннәре кандидаты, доцент Р.Л. Зәйни

*Рецензентлар:*

филология фәннәре кандидаты, доцент И.Ф. Фәттахов

филология фәннәре кандидаты, ассистент А.Ф. Галиәхмәтова

**Галиева Р.М., Сабирова Л.Р.**

**Фәнни язма эшләр, практика. Татар журналистикасы бүлеге студентлары өчен хисап тәртибе: укыту-методик кулланмасы** / Р.М.Галиева, Л.Р.Сабирова. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2014. 123 б.

Укыту-методик кулланмасы татар журналистикасы бүлегендә язма фәнни эшләрнең төрләре белән таныштыра, аларны башкару үзенчәлекләренә өйрәтә, шулай ук биредә курс һәм диплом эшенә куела торган таләпләр һәм кагыйдәләр искәртелә, темалар тәкъдим ителә. Кулланмада җәйге укыту-таныштыру, җитештерү һәм диплом алды практикалары буенча да методик мәгълүмат бар. Шулай ук үзләштерелә торган дисциплиналар буенча зачет һәм имтиханнарга әзерләнү өчен якынча сораулар һәм әдәбият исемлекләре дә тупланган.

Кулланма югары уку йортларының «Журналистика» белгечлеге буенча белем алучы студентларга тәкъдим ителә.

**ЭЧТӘЛЕК**

**КЕРЕШ..........................................................................................3**
**ФӘННИ ЭШНЕҢ БАСКЫЧЛАРЫ....................................................6**
**ФӘННИ ЭШНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ ......................................................7**
**ФӘННИ ЭШНЕҢ ФОРМАСЫ.........................................................10**
**ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ БИБЛИОГРАФИЯ АППАРАТЫ.......................10**
**ЯКЛАУ ТӘРТИБЕ...........................................................................16**
**БӘЯЛӘМӘ ЯЗУ ТӘРТИБЕ.................................................................16**
**БАЛЛ-РЕЙТИНГ СИСТЕМАСЫ РЕГЛАМЕНТЫ................................17**
**ТИТУЛ БИТЕ ҮРНӘГЕ ......................................................................19**
**ЭЧТӘЛЕК ҮРНӘГЕ..............................................................................21**
**КУРС ЭШЕ ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ БӘЯЛӘМӘСЕ.......................................22**
**КУРС ЭШЕНӘ РЕЦЕНЗЕНТ БӘЯЛӘМӘСЕ.........................................23**
**РЕЦЕНЗЕНТ БӘЯЛӘМӘСЕ ҮРНӘГЕ...................................................24**
**ДИСЦИПЛИНАЛАРДАН ЗАЧЕТ ҺӘМ ИМТИХАН СОРАУЛАРЫ, ӘДӘБИЯТ, ИНТЕРНЕТ-ЧЫГАНАКЛАР...............................................25**
**КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЕ (ДИПЛОМ) ТЕМАЛАРЫ.......................................................................................... 74**
**УКУ БАРЫШЫНДА КУЛЛАНЫРГА МӨМКИН БУЛГАН САЙЛАНМА ФӘННИ ХЕЗМӘТЛӘР ИСЕМЛЕГЕ...............................93**
**РЕДАКЦИЯДӘ ИҖАТ КӨНЕ ҺӘМ ПРАКТИКА ..............................112**
**«РЕДАКЦИЯДӘ ИҖАТ КӨНЕ»НӘ БӘЯЛӘМӘ ҮРНӘГЕ................121**
**ИҖАДИ ПОРТФОЛИО МАТЕРИАЛЛАРЫНА БӘЯЛӘМӘ ҮРНӘГЕ.....................................................................................122**
**ӘДӘБИЯТ.........................................................................................123**
**ИНТЕРНЕТ-ЧЫГАНАКЛАР...............................................................123**

# КЕРЕШ

Казан федераль университеты студенты үз сүзен, фикерен төгәл җөмләләр, дәлилләнгән фактлар белән җиткерә белергә тиеш. Моның өчен ул дүрт ел дәвамында дәрес-лекцияләр, практик дәресләр, мөстәкыйль һәм лаборатор эшләр барышында күнекмәләр ала. Бигрәк тә фәнни язма эш алымнары студентның мантыйкый фикерләвен үстерергә ярдәм итә.

Укытыла торган һәрбер фән үз эченә фәнни язма эшләрне туплаган. Нәзари (теоретик) белемне һәрвакыт гамәли (практик) эш белән беркетеп кую әһәмиятле.

Фәнни язма эш (доклад, контроль эш, реферат, курс һәм чыгарылыш квалификация (диплом) эше) студентның эрудициясен, сәләтен күрсәтә торган катлаулы фәнни иҗат нәтиҗәсе. Журналистика бүлеге студентлары ике төрдәге фәнни хезмәт башкара ала. Беренчесе – нәзари (теоретик), икенчесе – нәзари-иҗади.

**Нәзари** фәнни эштә студент журналистика теориясе, тарихы, матбугат типлары, жанрлар, мәгълүмат чараларының төрләре, радио, телевидение һәм электрон басмаларның мөһим мәсьәләләрен соңгы фәнни тикшеренү нәтиҗәләренә таянып анализлый. Шулай ук бүгенге социаль-икътисадый шартларда халыкара журналистиканың үсеш юллары тикшерелә.

**Нәзари-иҗади** эшнең үзенчәлеге шунда ки, тикшерүнең объекты итеп авторның үз иҗаты алына. Әйтик, нинди дә булса темага бәйле язмалар тупланмасы, бер үк жанрдагы әсәрләр. Иҗади фәнни эш автордан гаммәви мәгълүмат чараларында (алга таба – ГМЧ) басылган хезмәтләре булу белән беррәттән, төпле тематик белем, фәнни эзләнүләр таләп итә. Әлбәттә, студентның төп иҗатчы буларак үзен тәкъдим итүе мактауга лаек, әмма бу эш җиңел дип уйлаучылар ялгыша. Ул үз иҗатын мәгълүмат чараларының гомуми эшчәнлеге яссылыгында анализлый һәм үрнәк булырдай тәҗрибәле журналистлар иҗаты белән чагыштыра.

Курс һәм диплом эше мөстәкыйль рәвештә языла. Ул студенттан киеренке хезмәт, тикшерү осталыгы һәм хатасыз башкаруны, әдәбият һәм чыганаклар исемлеген соңгы елларда кабул ителгән дәүләт стандартларына туры китереп язуны таләп итә. Шул җәһәттән, бу укыту-методик кулланманың фәнни эшне язганда, мәсәлән, теманы ничек сайларга, ничек төзергә, чыганаклар, астөшермәләр белән эш иткәндә, гомумән, курс һәм диплом эшен яклауга әзерләү, яклау вакытында файдасы тияр, дип уйлыйбыз.

Студентлар журналистика бүлегендә **фәнни доклад, контроль эш** һәм **реферат** яза. Гадәттә, бу төр эшләр уку семестры барышында башкарыла. Зачет яисә имтихан алдыннан бәяләнә.

Контроль эш югары уку йорты укытучысы тарафыннан әзерләнә, ул төрле формада булырга мөмкин. Мәсәлән, «Әдәби-публицистик жанрлар (сатира)» дисциплинасын үзләштерүче студентлар мәзәк, сатирик характеристика һәм фельетон язу буенча контроль эш башкара. Соңгы вакытта тест рәвешендә тәкъдим ителгән контроль эш төрләре гамәлгә керә башлады.

Реферат – татар журналистикасы кафедрасында иҗадилыкны таләп итә торган фәнни эш төре. Ул язмача башкарыла. Фәнни хезмәткә куелган таләпләр, бурыч-максатлары, теманың мөһимлеге, ягъни актуальлеге ачыклана. Мәсәлән, «Журналист осталыгы» дисциплинасыннан сезгә реферат язарга тәкъдим ителде, ди. Студент «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире, элек «Татарстан яшьләре»нең танылган журналисты Миңназыйм Сәфәров иҗатын өйрәнергә теләк белдерә. Рефератның герое турында язганчы, ул аның язмаларын укырга, бер үк вакытта профессор В.З.Гарифуллинның «Журналист осталыгы» (2004), «Журналист эшчәнлеге нигезләре» (2009) кебек хезмәтләре белән танышырга тиеш була. Әмма әлеге хезмәтләр белән генә чикләнү ярамый, Россия яки башка илләр журналистикасында аерым урын алган журналистларның иҗатын өйрәнгән фәнни мәкаләләр, җыентыклар да сезгә методологияне ачыклаганда ярдәмгә килергә, үрнәк булып торырга тиеш. Нәзари яктан шул рәвешчә әзерләнгәннән соң, студент М.Сәфәровның үзе белән очрашып сөйләшә ала.

Нәзари-иҗади рефераттан тыш, журналистика тарихына һәм вакытлы матбугаттагы жанрларның төрләре һәм төзелеш үзенчәлекләре буенча нәзари реферат та язылырга мөмкин. Реферат укыту барышының аерылгысыз бер өлеше санала, чөнки лекциядә, практик дәрестә алынган белем бергә туплана. Реферат студентның уйлау сәләтен яхшырта, тупланган белемне нигезле кулланырга булыша.

Доклад, контроль эш, реферат, курс һәм диплом эшен язу студенттан зур игътибар таләп итә. Фәнни җитәкчеләрегезнең киңәшләрен тыңлап, нәзари һәм нәзари-иҗади эшләрне семестр дәвамында үтәп барырга тырышыгыз. Фәнни язма эшне язу – җитди гамәл, аңа җаваплы карарга кирәк!

Укыту-методик кулланмада фәнни язма эш төрләре белән беррәттән, укытыла торган фәннәрдән сораулар, әдәбият исемлеге, интернет-чыганаклар, курс һәм чыгарылыш квалификация (диплом) эше темалары да тәкъдим ителә. Татар журналистикасы кафедрасы укытучыларының фәнни хезмәтләре белән дә танышырга һәм аларны фәнни язма эшләрдә кулланырга мөмкинлек бирә.

Хезмәттә «Журналистика» юнәлеше өчен бик әһәмиятле саналучы практика үтү таләпләре белән дә танышырга була. «Редакциядә иҗат

көне», «Диплом алды практикасы» безнең укыту барышына нык бәйләнгән. Дүрт ел дәвамында студент иҗади эш башкарырга, ягъни язмалар бастырырга һәм уку елы дәвамында ике тапкыр аттестация үтәргә тиеш. Бу хакта сез «Практика» бүлегендә тулырак таныша аласыз.

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында уку шактый катлаулы, биредә киңкырлы белем бирелә. Шул ук вакытта студентның тырышлыгы да таләп ителә, чөнки теоретик белемне вакытында практик эшләр белән беркетеп барырга кирәк.

## ФӘННИ ЭШНЕҢ БАСКЫЧЛАРЫ

Фәнни язма эш *тема сайлаудан* башлана. Аны студент үзе сайларга яисә ул фәнни җитәкче, яисә кафедра тарафыннан тәкъдим ителергә

мөмкин. Курс эше буенча темалар уку елы башында кафедра утырышында раслана. Чыгарылыш квалификация эше темалары исә алданрак, узып баручы уку елының азагында раслана. Моның өчен булачак дипломчы сайларга теләгән теманың исемен һәм фәнни җитәкчесен күрсәтеп кафедра мөдире исеменә гариза язарга тиеш.

Тема, беренче чиратта, студентның үзендә кызыксыну уятырга тиеш. Аның ялгыш сайлануы фәнни эшнең дәвамлылыгын һәм нәтиҗәлелеген киметә. Шуңа күрә беренче курстан ук диплом эше дәрәҗәсенә җиткерерлек курс эше темасын сайлау яхшырак.

Икенче баскыч – китапханәдә, архивларда эшләү, ягъни *материал туплау*. Тема расланганнан соң, эшнең хронологик кысалары билгеләнә, тикшерү объекты тәгаенләнә. Фәнни җитәкче сайланган темага кагылышлы әдәбият исемлеген тәкъдим итәргә мөмкин. Китапханәдә эшләү барышында студент тематик каталоглардан файдалана ала, ягъни үзе өйрәнә торган темага кагылышлы барлык фәнни әдәбиятны карап чыга, шулар арасыннан үзенә аеруча кирәклеләрен сайлый. Иң мөһиме, авторның фамилиясен һәм инициалларын, баш исемен, басылып чыккан елын, шәһәрен, нәшриятын, китапның бит санын дөрес итеп күчереп язарга кирәк. Дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп, фәнни эшнең чыганакларын һәм әдәбият исемлеген тутырырга кирәк. Архив документларының саклану урынын, нинди сан астында, кайсы бүлектә урнаштырылган икәнлеген ачыклау мөһим.

Тикшерү объекты булып газета-журналларда басылган язмалар, радио һәм телевидение тапшырулары сайлана. Әлбәттә, аерым бер курс эшендә бик күп еллар дәвамында басылган яисә эфирда яңгыраган материалларны колачлау мөмкин түгел. Димәк, тикшерү өчен сайланган текстлар вакыты чикләнгән хронологик тәртиптә алына. Материалны темада күтәрелгән проблема яссылыгында укырга кирәк, фактларга тирәнтен анализ таләп ителә. Темагаярашлы берничә китаптан тыш, шулай ук газета-журналда басылган әлеге мәсьәләгә кагылышлы фәнни мәкаләләргә дә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Башка автор фикере сылтама (цитата) рәвешендә куштырнаклар эчендә бирелә. Студентның максаты проблемаларны күрсәтү генә түгел, үз карашыңны билгеләү, журналист эшчәнлегенә бәя бирү, проблеманы ачуда аның үзенчәлеген табу, аңлау, анализлау. Кимчелекле яклары булса, сәбәпләрен ачыклау, дәлилләү, төзәтү юлларын әйтү.

Өченче баскыч – *план төзү*. Аны, һичшиксез, фәнни җитәкче белән бергәләп камилләштерергә кирәк. Фәнни язма эш, гадәттә, өч зур кисәктән тора: кереш, төп өлеш, йомгак.

## ФӘННИ ЭШНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Фәнни эшнең төзелеше кереш, төп өлеш, йомгак, әдәбият һәм чыганаклар исемлеге, кушымтадан тора. Тема сайлаганнан соң, эчтәлек планы әзерләнә.

*Керештә* теманың ни өчен сайлануы, аның актуальлеге, фән өчен кирәклеге нигезләнә, хезмәтнең максат-бурычлары билгеләнә, тикшеренүнең методологиясе, анализ алымнары ачыклана, фәнни эшнең гамәли әһәмияте дәлилләп бирелә, файдаланылган нәзари әдәбиятка күзәтү ясала, чыганаклар даирәсе тәгаенләнә, хезмәтнең төзелешенә кыскача күзәтү ясала.

**Кереш язу үрнәге**

## Кереш

**Теманың актуальлеге.** Журналистика эшчәнлеге аралашу ихтыяҗы тугач, икътисади элемтәләр, сәүдә барлыкка килгәч, мәгълүматны күбәйтеп тарату мөмкинлеге булдырылгач аерылып чыккан. Аралашу ихтыяҗы борынгы кабиләләр заманында хасил булган. Безнеңчә, аралашу – ул журналистиканың төп алшарты булып тора.

Кешенең аралашу ихтыяҗы кайчан барлыкка килә икән соң? Моны ачыклар өчен галимнәр сабый тууның уналтынчы көненнән алып систематик күзәтү үткәргән. «Безнең күзәтүләрнең нәтиҗәләре шуны күрсәтә: бала дөньяга килгәч үк олылар белән аралашмый. Ә ике айдан соң нарасый зурлар белән бәйләнешкә керә, моны аралашу дип санап була»[1].

«Аралашу – уй-фикереңне бер-береңә җиткерешеп аңлашу, ул нигездә, тел белән фикереңне белдерү, хәбәр итү һәм тәэсир итү»[2]. Әйе, чыннан да, аралашу ярдәмендә без төрле яңалыкларны, кызыклы хәбәрләрне, гыйбрәтле хәлләрне белә алабыз. Журналист һәрвакытта мәгълүмат белән эшли. Төп коралын – мәгълүматны кулланыр өчен, әлбәттә, аралашу зур роль уйный. Журналистиканың кайсы гына өлкәсен алма, кешеләр белән аралаша белү барлык жанрларда да кирәк.

Интервью катлаулы сөйләм жанрының аерым төр коммуникатив чарасы буларак кабул ителә. Сөйләм категориясе буларак интервью татар телен баетуга китерә. «Элек тар даирәдә генә кулланылган термин, профессионализм, диалектизм, фразеологизмнар, «канатлы сүзләр» хәзер

---

[1] Лисина М.И. Проблемы онтогенеза общения. М.: Педагогика, 1986. С. 31–57.
[2] Низамов И.М. Уем – тел очында... (Сөйләм һәм массакүләм аралашу // Беренче кисәк. Татар сөйләме нигезләре). Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. Б. 11.

интервью жанрында киң һәм актив күренә башлады»[3]. Жанр, һичшиксез, аралашуга корылган. Шуңа күрә бу очракта аралаша белү культурасын, этика, дипломатия кагыйдәләрен белү зарури.

Интервью ГМЧда даими басыла, күрсәтелә, ишеттерелә. Җавап алырга юнәлтелгән сорауларны белү, аеру, кайсысын кайчан бирергә кирәк икәнен чамалау – әзерлек дәрәҗәсен күрсәтә. Шулай ук сорауларны төзи белү үзе үк күп әйбер турында сөйли. Безнең дә моның серләренә төшенәсебез килә. Шуңа күрә курс эшебезгә «Интервьюда сорауларның төп функциясе, аларны әзерләү үзенчәлеге» дигән теманы сайладык.

Бу теманы хәзер дә актуаль дип саныйбыз, чөнки текст аша аудиториягә факт, вакыйга һәм күренешләргә карата төрле фикерләрне бер шәхес авызыннан җиткерергә мөмкин. Интервью күпчелек очракта геройның туры сөйләменнән тора.

Журналистикада интервью мәгълүматның беренчел чыганагы итеп билгеләнә, аны беренчелеккә мобиль, төгәл, оператив булуы илтә. Хәзерге дөньяда кешеләргә җиткерелә торган мәгълүмат бик күп, ул тизлеккә бәйле. Заманча журналистика укучыларга анализга караганда, күбрәк фактлар җиткерә. Шуңа да журналистлар арасында әлеге жанр популяр, актуаль исәпләнә.

**Проблеманың өйрәнелү дәрәҗәсе.** Интервью хәбәри жанрлар арасында иң популярларыннан санала. Беренчедән, ул аралашуга корылган. Икенчедән, аудиториягә дә мондый язмаларны укырга кызыграк. Шуңа күрә интервью галимнәр тарафыннан күп өйрәнелгән темаларның берсе. Мәсәлән, бу жанрны М.Н.Ким, С.А.Белановский, В.З.Гарифуллин, Л.Р.Сабирова анализлаган.

Курс эшенең **тикшеренү объекты** итеп журналистика фәненең интервью жанры алынды.

**Тикшеренү предметы** булып интервьюда сорауларның төп функциясе, аларны әзерләү үзенчәлеге мәсьәләсе тора.

**Курс эшенең максаты** – интервьюда сорауларның функциясен, аларны әзерләү үзенчәлеген өйрәнү.

**Курс эшенең бурычлары:**

1) интервью жанры турында нәзари мәгълүмат тупларга;
2) сорауларның төрләрен күзәтергә;
3) сорауларның функциясен билгеләргә;
4) интервью сорауларын әзерләүне ачыкларга.

---

[3] Сабирова Л.Р. Речевые особенности жанра интервью на татарском языке. Казань: Казан. ун-т, 2011. С. 16.

**Курс эшенең фәнни-нәзари методологик нигезе** булып М.Лукинаның «Технология интервью», Л.Р.Сабированың «Речевые особенности жанра интервью на татарском языке» хезмәтләре торды.

**Курс эшенең фәнни методлары.** Фәнни эш тасвирлау, анализлау, күзәтү алымнарына нигезләнеп башкарылды. Тасвирлау методы интервью сорауларының, аларның функциясен күрсәтүгә юнәлтелгән. Анализлау методы исә төрле интервьюларны тикшергәндә кирәк. Күзәтү методы газета-журналларда басылып чыккан әңгәмәләрне карап чыгу, бәя бирүгә юнәлгән.

**Курс эшенең яңалыгы.** Интервью жанры турындагы мәгълүматны системага салу, 2012–2014 елларда татар матбугатында басылып чыккан интервьюларда сорауларның төрләрен ачыклау.

**Курс эшенең гамәли әһәмияте.** Югары уку йортларында белем алучы студент, журналистлар өчен кирәкле, файдалы булыр дип уйлыйбыз.

**Курс эшенең чыганаклары** булып «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Сәхнә», «Казан утлары» басмаларының 2012–2014 елгы саннарында дөнья күргән һәм «Матбугат.ру», «Тамаша.ру» сайтларына урнаштырылган интервью текстлары кулланылды.

**Курс эшенең төзелеше** кереш, ике бүлек, йомгак, кулланылган әдәбият исемлегеннән һәм чыганаклардан тора.

Бүлекләр исә бүлекчә һәм параграфлардан торырга мөмкин. Бүлек, бүлекчә исемнәре фәнни хезмәтнең темасы белән тәңгәл килергә тиеш түгел. Һәр бүлек ахырында кыска нәтиҗәләр ясап барыла.

*Йомгакта* фәнни тикшерүгә нәтиҗә ясала, өйрәнгән проблемага бәйле рәвештә студентның үз тәкъдимнәре дә урын алырга мөмкин.

Дүртенче баскыч – *фәнни эшне башкару.* Студент куелган максат-бурычлар нигезендә өйрәнелә торган объектны анализлый, классификацияли, нәтиҗәләр чыгара.

Бишенче баскыч – эшне яклау. Фәнни эшнең караламасын студент яклауга якынча 15–20 көн кала җитәкчесеннән тикшертә, хаталарны төзәтә, аннары акка күчереп бара. Титул битенә башта үзе кул куя, фәнни җитәкчесенең имзасын (диплом эшенә – кафедра мөдиренең дә имзасын) ала һәм рецензентка тапшыра. Курс эшенә рецензияне студентның төркемдәше, курсташы яза ала, ә диплом эшенә кафедра тарафыннан билгеләнгән оппонент бәя бирә.

## ФӘННИ ЭШНЕҢ ФОРМАСЫ

Фәнни эш компьютерда Word форматында, Times New Roman гарнитурындагы шрифт белән 14 кегль үлчәмендә, 1,5 интервал белән җыела, А4 форматындагы кәгазьнең бер ягына бастырыла. Битнең сул ягында 2,5 см, уң ягында 1см, өстә 2 см, аста 2 см буш ара калдырыла.

Бит саны титул битеннән санала, әмма аңа да, «эчтәлек» битенә дә сан сугылмый. Фәнни эшнең кереше 3нче биттән башлана. Бүлек яисә параграф исемнәрен төп текстан өстән, астан ике юл һәм калын шрифт белән аерырга кирәк. Һәр бүлек яңа биттән башлана. Бүлек, бүлекчә, параграф һ.б. исеменнән соң нокта куелмый.

*Беренче бит* – фәнни язма эшнең титул бите һәм анда югары уку йортының исеме, кафедра исеме, тема, эшне язучының исем-фамилиясе, фәнни җитәкченең гыйльми дәрәҗәсе, вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары, шәһәр исеме, язылган ел күрсәтелә.

*Икенче биттә* – эчтәлек. Ул аерым бүлекләрнең, параграфларның билгеле бер тәртиптә килүен, аларның кайсы битләрдә урнашуын күрсәтә.

*Әдәбият исемлеге* фәнни хезмәтнең йомгак өлешендә бирелә һәм ул түбәндәге таләпләргә буйсынырга тиеш: башлап сайлаган теманы анализлау өчен тулаем кулланылган әдәбият исемлеге языла, аннары фәнни эштә алынган мисаллар яисә күзәтелгән чыганаклар исемлеге бирелә.

## ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ БИБЛИОГРАФИЯ АППАРАТЫ

Әдәбият һәм чыганаклар алфавит тәртибендә яки хронологик тәртиптә төзелә. Кулланылган әдәбият исемлеге дөрес булсын өчен, китапханәдә эшләгәндә, китап турында мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат күчереп алу кирәк. Мәсәлән, һәр китапның форзац өлешендә китапны бастыручы, ничәнче елда нәшер ителгәне, бит саны хакында мәгълүмат була. Фәнни эшне башкаручы үзе өчен кечкенә генә каталог та әзерли ала. Чөнки фән өлкәсендә эшләүчеләр кулланылган әдәбиятны шул рәвешле саклый.

Китапның чыгарылыш мәгълүматларыннан тыш, үзегез кулланырга теләгән сылтаманың кайсы битләрдә булуын да язып кую кирәк. Боларны фәнни эшкә әзерлек барышында махсус дәфтәргә теркәп бару да яхшы булыр иде. Фәнни хезмәтне яза башлагач, теге яки бу авторның әйткән фикерләрен исбатларга яки кире кагарга мөмкин, шул чакта сезгә махсус дәфтәрегез ярдәм итәчәк тә инде.

Нәшриятләрдә сылтамаларны ГОСТ Р 7.0.5 – 2008 таләпләре буенча, ә әдәбият исемлеген ГОСТ 7.1 – 2003кә туры китереп күрсәтү гадәткә кергән. Без исә, буталчыклык килеп чыкмасын өчен, икесен дә –

сылтамаларны да, әдәбият исемлеген дә ГОСТ Р 7.0.5. – 2008гә нигезләнеп тутырырга киңәш итәбез.

**Әдәбият**
(ГОСТ Р 7.0.5. – 2008)

**Авторы берәү булганда,** әдәбият исемлегендә китап турындагы мәгълүматны болай итеп күрсәтергә кирәк:

Гарифуллин В.З. Каләм көче (Татар журналистларының текст төзү осталыгы) Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010. 160 б.

Тертычный А.А. Аналитическая журналистика: учеб. пособие для студентов вузов. М.: Аспект Пресс, 2010. 352 с.

**Ике автор язган китапны кулланганда:**

Лазутина Г.В., Распопова С.С. Жанры журналистского творчества: учеб. пособие для вузов. М.: Аспект Пресс, 2011. 320 с.

**Авторлар өчәү булган очракта:**

Орлов А.Б., Латыпов Л.Д., Творогов И.И. Психологические основы воспитания. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2000. 80 с.

**Дүрт һәм аннан да күбрәк автор катнашындагы китап хакында мәгълүмат болай бирелә**:

Изучение и преподавание отечественной истории в Казанском университете / В.В.Астафьев [и др.]. Казань: Из-во Казан. ун-та, 2003. 180 с.

**Җыентык**

Современное коммуникационное пространство журналисткой науки, практики и образования: контуры и реальность новых медия. Выпуск 5: сборник научных статей / под ред. В.З.Гарифуллина, Е.С.Дорощук. Казань: Казан. ун-т, 2014. 192 с.

**Җыентык эчендәге язма**

Беломоина Н.А. Милли журналистиканың торышы // Татар журналистикасы XXI гасырда. Үсеш юллары: фәнни-гамәли конференция материаллары, 2011 ел, 11 февр. Казан: Казан ун-ты, 2011. С. 6–10.

**Күп томлы басма**

Гегель Г.В.Ф. Соч. М., 1939. Т. 4. С. 32.

**Журналда басылган мәкалә**

Тагиров И. Мирсаид Султан-Галиев: «Признания» // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2011. №3/4. С. 57–68.

**Диссертация**

Сабирова Л.Р. Речевые особенности жанра интервью на татарском языке (на материале современных СМИ): дис. … канд. филол. наук. Казань, 2010. 221 с.

**Диссертациянең авторефераты**

Сабирова Л.Р. Речевые особенности жанра интервью на татарском языке (на материале современных СМИ): автореф. дис... канд. фил. наук. Казань, 2009. 23 с.

**Рәсми документ**

Конституция Российской Федерации: офиц. текст. М.: Маркетинг, 2001. 39 с.

**Конференция материаллары**

Закирова А.Р. Технологии политического PR // Итоговая научно-образовательная конференция студентов Казанского федерального университета 2013 года: сборник статей [в 5 т.] / Мин-во образования и науки; Казанский (Приволжский) федеральный ун-т. Казань: Казан. ун-т, 2013. Т.5: Институт филологии и искусств, факультет журналистики и социологии, Институт педагогики и психологии. С.153-155.

**Газетадан мәкалә**

Муллаянова Р. Сугыш санарга өйрәтте // Ватаным Татарстан. 2012. 9 март.

Шәрифуллин Н. Һәр дәвернең үз коллары // Ватаным Татарстан. 2014. 19 апр.

**Интернеттан алынган язмалар түбәндәгечә бирелә:**

Официальные периодические издания: электронный путеводитель / Рос. нац. б-ка, Центр правовой информации [СПб], 2005–2007. URL: http://www.nlr.ru/lawcenter/izd/index.html (дата обращения: 18.01.2007).

**Телевизион тапшыру**

Халкым минем / «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2012. 2 апр., 19 сәг. 15 мин.

**Телевизион реклама**

[Болгар радиосы рекламасы] / «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2012. 29 март, 18 сәг. 18 мин.

**Радиотапшыру**

Тел күрке сүз. ТДТРК. 2002. 7–15 апр. 12 сәг. 15 мин.

**Китаплар турында мәгълүмат биргәндә, Мәскәү һәм Санкт–Петербург шәһәрләренең атамалары кыскартып бирелә.**

М., СПб.

**Гаммәви мәгълүмат чараларының хронологиясен биргәндә, ай исемнәре кыскартыла:**

Гыйнвар – гыйнв.,
февраль – февр.,
март (кыскартылмый)
апрель – апр.,
май (кыскартылмый)
июнь (кыскартылмый)
июль (кыскартылмый)
август – авг.,
сентябрь – сент.,
октябрь – окт.,
ноябрь (кыскартылмый),
декабрь – дек.

**Чыганаклар**

**Чыганакларны күрсәткәндә шул ук шартлар саклана. Әйтик, газета язмасы, фәнни әдәбият яки чыганак буларак кулланылса да библиографиядә болай күрсәтелә:**

Шәкүрова Д. Ярамир Низаметдинов: «Татар җырына сусап үстем» // Ватаным Татарстан. 2014. 19 апр.

**Сылтама һәм астөшермәләр**

**Курс эшен язганда кулланылган сылтаманың чыганагы искәрмә итеп күрсәтелә. Ул өч төрле юл белән башкарыла: астөшермә рәвешендә, текст эчендә һәм текст азагындагы әдәбият исемлегенә сылтама ясау ысулы белән.**

**Астөшермә**

Зәйни Р.Л. Журналистның һөнәри этикасы: укыту-методик кулланмасы. Казан. 2014. С. 34–35.

**Бер үк материал шул ук биттә берничә мәртәбә кабатланса, хезмәтнең исеме тулысынча бер мәртәбә генә языла, ә калган очракта болай куела:**

Там же. С. 54.;   (Шунда ук. Б.10.)

**Текст эчендәге искәрмәләр**

**Текст эчендә әдәбият исемлегенә, цитаталарга сылтама берничә төрле вариантта язылырга мөмкин. Фәнни эш барышында аның бер төрен генә куллану дөрес.**

«Ни кызганыч, бу сезонда театрларда югалтулар да шактый булды[4]».

**Шулай ук чыганак турындагы мәгълүмат китерелгән мисалдан соң языла** (Шәһри Казан. 2012. 30 март.)

**Чыганак күп тапкыр кабатланганда, аны кыскартып бирергә була:**

Мәсәлән, «Без «Шәһри Казан» газетасын чыганак буларак кулландык (алга таба – Ш.К.)».

**Бер үк китапка берничә тапкыр мөрәҗәгать иткәндә, искәрмәләр болай күрсәтелә:**

Низамов И.М. Күрсәтелгән хезмәт. Б. 25.

Шунда ук. Б. 41.

**Текст азагындагы әдәбият исемлегенә сылтама ясаганда, хезмәтнең әдәбият исемлегендәге саны шакмаклы җәяләр эчендә күрсәтелә:**

«Бу проблема Р.У.Әмирханов [1] тарафыннан җентекле өйрәнелгән».

**Фәнни хезмәтнең аерым битләренә искәрмә ясаган очракта түбәндәгечә язалар:**

«И.М.Низамов аларны газетизм дип билгели [4, Б. 66]».

**Беренче сан әдәбият исемлегендә әлеге китапның ничәнче булып язылганын аңлатса, икенчесе бит санын күрсәтә.**

**Бер авторның берничә хезмәтенә яисә берничә галим китабына искәрмә ясалганда, җәяләр эченә нокталы өтер аша бу хезмәтләрнең әдәбият исемлегендәге тәртип санын куялар:**

«Татар журналистикасы фәнендә әлеге проблемага карата шактый хезмәтләр язылган. [4; 11; 13]».

**Архив документлары белән эш иткәндә**

**Архив документына библиографик сылтама аның кайда урнашканлыгын ачыклый. Документлар архив, музей һәм китапханәләрдә саклана.**

---

4 Шәһри Казан. 2012. 30 март.

**Документның исеме, эзләү мәгълүматлары, объектның урынына сылтама, саклау берәмлеге күрсәтелә.**

**Теге яки бу документны эзләгәндә, архив исеме, фонд, опись номеры, эшнең бите языла. Бөтен эзләү мәгълүматлары нокталар аша бирелә:** Мәсәлән, ОР РНБ. Ф. 316. Д.161. Л.1.

РО ИРЛИ. Ф. 568. Оп.1. №196. Л. 18–19 об.

**Архив исемнәре кыскартылып та күрсәтелергә мөмкин. Мәсәлән, текстта берничә мәртәбә кабатлаулар булганда:**

Арх. РГБ.

Арх. кинофотодокументов

НА РТ (Нац. Арх. Республики Татарстан).

**Бит асты һәм текст азагында документ хакында мәгълүмат түбәндәгечә бирелә. Ул эзләү мәгълүматларыннан ике кыек сызык белән аерыла:**

7

Розанов И.Н. Как создавалась библиотека Исторического музея: докл. на заседании Ученого совета Гос. публ. ист. б-ки РСФСР от 30 июня 1939 г. // ГАРФ. Ф. А–513. Оп. 1. Д. 12. Л.14.

36

Материалы об организации Техникума печати при НИИ книговедения // ЦГАЛИ СПБ. Ф. 9. ОП. 1. Ед. хр. 109.

4. Северо-Западное бюро ЦК ВКП(б). Общий отдел. Протоколы // ЦГАИПД. Ф. 9. Оп. 1. Ед. хр. 109.

28. Логинов М.Н. Письма (9) С.Д. Полтарацкому. 1857–1860 гг. // ОР РНБ. Ф. 603 (С.Д.Полтарацкий). Д. 145. 15 л.

Фәнни эштә искәрмәләр куллану һәм библиография аппаратын белү – барысы да сезнең фәнни эшне башкарганда кулланылган, укылган, өйрәнелгән әдәбият исемлеген төзү өчен кирәк иде. Чөнки кечкенә генә, мәсәлән, реферат, доклад кебек фәнни эшләрне язганда да, сез әдәбият исемлеген күрсәтергә тиеш. Бу исә темага карата башкаларның фикерен белү, алар белән килешү яки бәхәскә керү өчен кирәк. Аннан соң теге яки бу теманы сезгә кадәр дә өйрәнүчеләр булган, шуңа күрә темаңны тулырак күзаллау өчен дә әдәбиятка күзәтү ясау мөһим.

## ЯКЛАУ ТӘРТИБЕ

Гадәттә, студентлар фәнни язма эшне махсус график буенча курсташлары һәм комиссия әгъзалары алдында яклый. Студент 7–10 минут эчендә үз эшенең темасы, максат-бурычлары һәм төп нигезләмәләре, нәтиҗәләре белән таныштыра. Аннары студентка сораулар бирелә. Җаваплардан соң рецензент 3–4 минут сөйли, эшкә үз бәясен бирә, теманың дөрес сайлану-сайланмавы турында әйтә, уңышлы-уңышсыз якларын күрсәтә. Фәнни эш авторы аның да сорауларына җавап бирә, тәнкыйди фикерләренә, теләк-тәкъдимнәренә мөнәсәбәтен белдерә.

Курс эшенә бәяне укытучылардан торган комиссия, ә диплом эшенә – Дәүләт аттестация комиссиясе куя.

Әлбәттә, эшне бәяләгәндә комиссия тәкъдим ителгән фәнни хезмәтнең башкару сыйфатын, дәүләт стандартларына туры китереп әзерләнгәнлеге белән беррәттән, студентның кыска гына вакыт эчендә үз хезмәтенең асылын аңлата белүен, фәнни дискуссия барышында югалып калмавын, аудитория алдында үз-үзен тотышын да исәпкә ала.

## БӘЯЛӘМӘ ЯЗУ ТӘРТИБЕ

Фәнни эшне яклар өчен аның башкалар тарафыннан укылган булуы, бәя бирелүе сорала. Курс эшләренә бәяләмәне төркемдәшең һәм гыйльми җитәкчең язса, диплом эшенә бәяләмәне кафедра тарафыннан билгеләнгән оппонент һәм фәнни җитәкче яза.

Бәяләмә (рецензия) язуның үз тәртибе бар. Фәнни җитәкче һәм төркемдәшеңнең бәяләмәсе түбәндәге сорауларны үз эченә ала. (**Алга таба бу үрнәкләр белән таныша аласыз.)** Чыгарылыш квалификация эшенә рецензент бәяләмәсе ирекле формада языла:

1. Фәнни эшнең эчтәлеге куелган максат-бурычларга, теманың актуальлегенә туры киләме?
2. Куелган сораулар нигезле дәлилләнгәнме?
3. Мөстәкыйль эшләү сыйфаты ни дәрәҗәдә?
4. Студент башкаларның хезмәтен өйрәнә һәм гомумиләштерүләр ясый алганмы?
5. Дөрес нәтиҗәләр чыгарылганмы?
6. Материалны өйрәнү дәрәҗәсе.
7. Рецензент тарафыннан башка сораулар да булырга мөмкин.
8. Фәнни эшнең кимчелекләре.
9. Фәнни эшнең киләчәктә кулланылышы.
10. Башкарылган эшкә билге.
11. Көне, имзасы.

# БАЛЛ-РЕЙТИНГ СИСТЕМАСЫ РЕГЛАМЕНТЫ

Кафедра утырышында фәнни эшне яклау графигы раслана һәм комиссия әгъзалары билгеләнә.

Гадәттә, 22 апрель көнне чыгарылыш квалификация эшенең язылу барышы, эшләнеше тикшерелә. Яклау алды комиссиясендә студент фәнни хезмәтенә хисап тота, сорауларга җавап бирә. Бу вакытка эшнең күп өлеше әзер булырга тиеш. Фәнни хезмәтнең һәм бүлек-бүлекчәләр исеме тәгаенләнеп бетәргә, һәртөрле төгәлсезлекләр ачыкланып төзәтелергә тиеш.

Яклау вакыты: һәр елның май-июнь айлары.

## Семестр дәвамында эш тәртибе

| № Тәртип саны | Эш төре | Вакыты | Балл (иң югары – max) |
|---|---|---|---|
| 1. | Вакытында тема сайлау; фәнни җитәкче белән аралашу | 15 окт. | **5** |
| 2. | Әдәбият һәм чыганаклар белән эшләү; диплом эшен планлаштыру | дек. | **30** |
| 3. | Фәнни җитәкче янына киңәшкә бару; диплом эшенең барышы белән таныштыру | уку елы дәвамында | **20** |
| 4. | Чыгарылыш квалификация эшенең вакытында үтәлеше һәм тапшырылуы | апр.-май | **5** |
| 5. | Чыгарылыш квалификация эшенең тематикасы буенча фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашып, чыгыш ясау (өстәмә балл) | гыйнв.-апр. | **5** |

## Аттестацияләү барышы

| №<br>Тәр-тип саны | Бәяләү критерияләре | Балл (иң югары – max) |
|---|---|---|
| 1. | Фәнни эшнең эчтәлеге куелган максат һәм бурычларга, теманың актуальлегенә туры килүе | **10** |
| 2. | Студентның мөстәкыйль эшләве, фәнни тикшерүнең үзенчәлеге | **5** |
| 3 | Чыганаклар һәм фәнни әдәбият белән эшләве | **5** |
| 4 | Чыгарылыш квалификация эшенең төзелеше, дәүләт белем стандартлары (ФГОС) таләпләренә туры килүе | **5** |
| 5 | Яклауда чыгыш ясау, сорауларга җавап бирү | **15** |

## Чыгарылыш квалификация эшен бәяләү

| **Аттестация төре** | **Балл (max)** |
|---|---|
| Семестр дәвамында эш тәртибе | **55** |
| Өстәмә балл | **5** |
| Яклау | **40** |
| Барлыгы: | **100** |

## Балларның билгедә чагылышы

| **Балл** | **Билге** |
|---|---|
| 33–54 | «Канәгатьләнерлек түгел» |
| 55–70 | «Канәгатьләнерлек» |
| 71–85 | «Яхшы» |
| 85–100 | «Бик яхшы» |

Көндезге бүлекнең 1, 2, 3 курс студентлары курс эшен 15–25 апрельдә яклый.

**Титул бите үрнәге**

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ЮГАРЫ ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМИЯЛЕ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ»

ГАММӘВИ КОММУНИКАЦИЯ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ФӘННӘР
ИНСТИТУТЫ
ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫ КАФЕДРАСЫ

Юнәлеш: 42.03.02. Журналистика
Профиль: «Гаммәви чаралары (милли журналистика)»

ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЕ

**ТАТАР МАТБУГАТЫН ПОПУЛЯРЛАШТЫРУДА
«MATBUGAT.RU» САЙТЫНЫҢ РОЛЕ**

Төгәлләнде
2014 елның «__»_________
___________________

Көндезге уку бүлегенең
4 курс, 1302 төркем студенты
Галиуллина Л.Р.

Яклауга чыгарылды
2014 елның «__»_________
___________________

Фәнни җитәкчесе:
филология фәннәре кандидаты
Галиева Р.М.

Яклауга әзер
2014 елның «__»________
___________________

Кафедра мөдире:
филология фәннәре докторы,
профессор Гарифуллин В.З.

Казан
2014

**Титул бите үрнәге**

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ЮГАРЫ ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМИЯЛЕ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ»

ГАММӘВИ КОММУНИКАЦИЯ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ФӘННӘР
ИНСТИТУТЫ
ТАТАР ЖУРНАЛИСТИКАСЫ КАФЕДРАСЫ

Юнәлеш: 42.03.02. Журналистика
Профиль: «Гаммәви мәгълүмат чаралары (милли журналистика)»

КУРС ЭШЕ

**ИНТЕРВЬЮ ЖАНРЫ – ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ СӨЙЛӘМ КАТЕГОРИЯСЕ**

| | |
|---|---|
| Төгәлләнде | Читтән торып уку бүлегенең |
| 2014 елның «__»_________ | 3 курс, 1392 төркем студенты |
| __________________ | Нуруллина Р.Р. |
| Яклауга чыгарылды | Фәнни җитәкчесе: |
| 2014 елның «__»_________ | филология фәннәре кандидаты |
| __________________ | Сабирова Л.Р. |

Казан
2014

**Эчтәлек үрнәге**

## Эчтәлек

**Кереш**..........................................................................................3

**Беренче бүлек.** Интервьюда сораулар..................................................6
1.1. Жанрлар системасында интервьюның урыны...............................6
1.2. Интервьюда сорауларның төп функциясе......................................8
1.3. Интервьюда сорауларның бүленеше............................................12

**Икенче бүлек.** Сорауларны әзерләү үзенчәлеге................................. 21
2.1. Интервьюда сорауларны бирү тактикасы....................................21
2.2. Сорау биргәндә проектив техника куллану алымы......................25
2.3. Сорауларны әзерләгәндә әңгәмәдәшкә тәэсир итү ысулы...........26

**Йомгак**..........................................................................................31

**Әдәбият**..........................................................................................33

**Чыганаклар**....................................................................................36

**Кушымта** .......................................................................................37

## КУРС ЭШЕ ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ БӘЯЛӘМӘСЕ

Тема ___________________________________________________________________

Автор (студент) _____________________________________________________

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Татар журналистикасы кафедрасы

Юнәлеш ______________________________________________________________

Профиль______________________________________________________________________

Фәнни җитәкчесе__________________________________________________________________

(Исем-фамилиясе, эш урыны, вазифасы, гыйльми дәрәҗәсе, фәнни исеме)

КУРС ЭШЕНЕҢ ФГОС/ГОС ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛҮ-КИЛМӘҮ КҮРСӘТКЕЧЕ

| Һөнәри әзерлеккә таләпләр | Туры килә | Нигездә туры килә | Туры килми |
|---|---|---|---|
| Курс эшен башкарганда бурычларны-максатларны уйлау һәм формалаштыру, анализлау, актуальлек һәм проблеманың килеп чыгу сәбәпләрен ачыклый белү | | | |
| Куелган бурычларны хәл итүнең өстенлекле якларын билгеләү | | | |
| Журналист мәгълүматын куллана белү | | | |
| Һөнәри эшчәнлек өлкәсендә мәгълүматны җыю, саклау һәм эшкәртүнең (редакцияләүнең) компьютер ярдәмендә тормышка ашырыла торган алымнарын куллану | | | |
| Тупланган мәгълүматны анализлау һәм аңлатып җиткерүнең (интерпретацияләү) мөмкинлекләрен дөрес бәяләү | | | |
| Вакытны нәтиҗәле файдаланып, эш тәртибен дөрес оештыру (максат-бурычларны, объект-предметны ачыклау, фәнни тикшеренүнең яңалыгын, актуальлеген, методологик нигезне билгеләү, эшнең планын төзү, мәгълүмат туплау, эшкәртү, текстны язу, нәтиҗә ясау) | | | |
| Исәп-хисап нәтиҗәләрен объектив бәяләү | | | |
| Аңлатып җиткерү (интерпретация) һәм тәҗрибә (эксперимент) ярдәмендә табылган мәгълүмат нәтиҗәләрен анализлый белү | | | |
| Анализ алымнарын белү | | | |
| Хезмәттәшләр, курсташлар белән аралаша белү, эшчәнлек алып бару | | | |
| Фәнни эштә дәлилләнгән дөрес нәтиҗәләргә ирешә белү | | | |
| Һөнәри юнәлештәге фәнни әдәбият куллану | | | |

Эшнең өстенлекләре___________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Кимчелекләре

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Нәтиҗә_______________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Фәнни җитәкчесе ______________________________________________________

2014 елның «____» ____________________

## КУРС ЭШЕНӘ РЕЦЕНЗЕНТ БӘЯЛӘМӘСЕ

Автор (студент) ___________________________________________________________________

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Татар журналистикасы кафедрасы

Юнәлеш ___________________________________________________________________________

Профиль___________________________________________________________________________

Эшнең темасы______________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

Рецензент_______________________________________________________________________________

_(Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, курсы)

Курс эшен бәяләү

| № | **Күрсәткечләр** | **5** | **4** | **3** | **2** | ***** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Теманың актуальлеге | | | | | |
| 2. | Күтәрелгән проблема, куелган бурычларның үтәлеше һәм урынлылыгы | | | | | |
| 3. | Кулланылган алымнарның үз-үзен аклавы | | | | | |
| 4. | Эшнең комплекслыгы, гомумһөнәри һәм махсус дисциплиналарда үзләштерелгән белемнәрне куллану дәрәҗәсе | | | | | |
| 5. | Текст төзелешендә төгәллек, аныклык, эзлеклелек һәм нигезлелек | | | | | |
| 6. | Заманча программалар һәм компьютер технологияләрен куллану дәрәҗәсе | | | | | |
| 7. | Хатасыз язу, фәнни язу стилен саклау, Дәүләт стандарты таләпләренә туры килү–килмәве | | | | | |
| 8. | График материалның сыйфаты, күләме, текстка туры килүе | | | | | |
| 9. | Эш нәтиҗәләренең нигезлелеге һәм дәлиллеге | | | | | |
| 10. | Нәтиҗәләрнең кабатланмаслыгы һәм яңалыгы | | | | | |

«*» бәяләнми (бәяләп булмый)

Эшнең өстенлекләре________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

Кимчелекләре (сораулар) ___________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Нәтиҗә____________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________________

________________

Рецензент ________________________________________________________________

2014 елның «______»_____________________

**Рецензент бәяләмәсе үрнәге**

**Көндезге бүлекнең 4 курс студенты Лилия Вәлиәхмәтованың «Хәзерге татар матбугатында укучыны җәлеп итү чаралары» дигән чыгарылыш квалификация эшенә бәяләмә**

Журналист эшчәнлегенең нәтиҗәле, тәэсирле булуы, сүз дә юк, бүген иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Заманча мәгълүмати чараларның артуы һәм күптөрле булуы басма матбугат алдына зур бурычлар йөкли. ГМЧ бу нисбәттән нинди эшләр башкара, нинди чаралар куллана? Бу хакта фәнни хезмәттә җентекләп аңлатыла.

Лилия Вәлиәхмәтова чыгарылыш квалификация эшендә нәтиҗәлелектән тәэсир итүгә һәм нәтиҗәлелекне арттыруда маркетинг коммуникациясенең ролен өйрәнә. Беренче бүлектә журналистикада нәтиҗәлелеккә ирешүдә максат кую, функцияләр, журналист язмасының мәгълүматлылыгы турында яза. Икенче бүлектә исә хәзерге татар матбугатында «промоушн» хакында сүз бара. Товар һәм хезмәт күрсәтү базарына карата кулланылган сүзнең мәгълүмат кырында урыны шулай ук үзенчәлекле билгеләнә. Бүген матбугат базарында үз товарыңны, ягъни басмаңны рекламалау һәм сату зур әһәмияткә ия, бу уңайдан республикада чыгып килүче татар матбугатының нинди эш башкарганын җентекләп өйрәнгән. Бу хакта кушымтада мисаллар үрнәк итеп бирелгән.

Фәнни хезмәт үзенең яңалыгы белән кызыклы. Хезмәтнең эчтәлеге, төзелеше бар, теле төзек. Басма матбугат чараларындагы мисаллар аша тема өйрәнелгән, контент анализ ясалган. Теманың актуальлеген тикшерү объекты итеп алынган басмалар ачык билгели. Проблеманың өйрәнелү дәрәҗәсе, чыгарылыш квалификация эшенең максаты, бурычлары анык булуы, гомумән, эчтәлекне баета.

Фәнни хезмәттә орфографик хаталар табылды. Алар автор тарафыннан төзәтелде. Төгәлсезлекләр фәнни эшне бизәми, бигрәк тә бүлек исемнәренең берничә төрле язылышы эшкә хилафлык китерергә мөмкин. Хата-кимчелекләр исәпкә алынгандыр, дип уйлыйм. Һәрхәлдә, үзара сөйләшү булды. Хезмәткә фәнни тирәнлек җитеп бетми, дигән тәэсир калды. Әдәбият исемлегенең дә кыска булуы шул турыда сөйли.

Гомумән, Л.Вәлиәхмәтованың хезмәтен уңай бәягә лаек дип саныйм. Киләчәктә фәнни уңышлар теләп калам.

«Ватаным Татарстан» газетасы корреспонденты,
«Бәллүр каләм-2012» журналистлар премиясе лауреаты
филол. фән. канд. Р.М.Галиева
14.05.14.

# ДИСЦИПЛИНАЛАРДАН ЗАЧЕТ ҺӘМ ИМТИХАН СОРАУЛАРЫ, ӘДӘБИЯТ, ИНТЕРНЕТ-ЧЫГАНАКЛАР

## «ЖУРНАЛИСТ ЭШЧӘНЛЕГЕ НИГЕЗЛӘРЕ (ГОМУМТЕОРЕТИК МӘСЬӘЛӘЛӘР)» дисциплинасы

1. Журналист иҗатының төрләре.
2. Журналист иҗатында фантазиянең роле.
3. Журналист иҗатының төп үзенчәлекләре.
4. Журналист иҗатында ассоциация.
5. Иҗатка сыйфатлама.
6. Журналистика әсәренең тема үзенчәлекләре.
7. Журналистның хокук һәм бурычлары.
8. Журналист иҗатында сиземләүнең әһәмияте.
9. Журналист иҗатында аралашу.
10. Журналист әсәрен иҗат итүнең үзенчәлекләре.
11. Журналист әсәрен бәяләү күрсәткечләре.
12. Текст тудыру баскычлары.
13. Күзәтү методы.
14. Иҗат ысулына гомуми сыйфатлама.
15. Журналистикада текст типлары.
16. Аралашуда туган киртәләрне җимеру алымнары.
17. Журналистикада фактологик текстлар.
18. Иҗат методы буларак интервью.
19. Журналист иҗатында фактларның роле.
20. Журналист әсәрен тудырганда фәнни методлар.
21. Журналистикада дәлилләүле текстлар.
22. Иҗат этәргече чыганаклары.
23. Журналистикада тасвири текстлар.
24. Журналист әсәренең эчтәлек  элементлары.
25. Журналистикада диалогик текстлар.
26. Журналистикада иҗат процессының төзелеше һәм буыннары.
27. Мантыйкый дәлилләүнең үзенчәлекләре.
28. Журналистикада эчтәлек һәм форма бердәмлеге.
29. Психологик дәлилләүнең үзенчәлекләре.
30. Журналист иҗатының объектив шартлары һәм субъектив факторлары.
31. Дәлилләүне үтемле итүнең текст чаралары.
32. Журналист иҗатында сәяси мәсьәләнең әһәмияте.
33. Журналист иҗатында конфликт.

34. Журналистның шәхси иҗади йөзе.
35. Әңгәмәгә әзерлек этаплары.
36. Журналист өчен мәгълүмат чыганаклары.
37. Татар журналистикасында текст оештыру осталары.
38. Журналист иҗатының психологик үзенчәлекләре.
39. Журналист иҗатында факт һәм образ нисбәте.
40. Документлар белән эшләү методы.
41. Татар журналистикасында дәлилләүле текст осталары.
42. Татар журналистикасында тасвири текст осталары.
43. Журналистикада социология методлары.
44. Журналист иҗаты психологиясенең үзенчәлекләре.
45. Журналист иҗаты методларына сыйфатлама.
46. Журналистика мәгълүматына сыйфатлама. Аның төзелеше.
47. Журналист осталыгының күрсәткечләре.
48. Журналистларның һөнәри аралашуы.
49. «Гаммәви мәгълүмат чаралары турындагы» Законның төп нигезләмәләре.
50. Журналистика ирегенең төп аспектлары.
51. Журналистикада авторлык хокукы.
52. Реклама турындагы хокукый-норматив документларның үтәлеше.
53. Редакция эшчәнлеген оештыруның хокукый нигезләре.
54. Журналист этикасының асыл принциплары.
55. Редакция коллективы, аның үзенчәлекләре.
56. Редакция эшен оештыру нигезләре.
57. Гаммәви мәгълүмат чаралары системасында телевидениенең урыны.
58. Гаммәви мәгълүмат чаралары системасында радионың роле.

## Әдәбият

1. Бакшин В.В. Основы журналистики: учеб. пособие. М.: Флинта; Наука, 2009. 54 с. URL: http://www.knigafund.ru/books/89742
2. Ворошилов В.В. Журналистика: базовый курс: учебник. СПб.гос. ун-т сервиса и экономики, фак. журналистики. 5-е изд.. СПб: Изд-во Михайлова В.А., 2006. 639 с.
3. Гарифуллин В.З. Журналист эшчәнлеге нигезләре: уку ярдәмлеге. Казан: КДУ нәшр., 2009.148 б.
4. Гарифуллин В.З. Журналист осталыгы. Казан: КДУ нәшр., 2004.175 б.
5. Ким М.Н. Журналистика. Методология профессионального творчества. СПб.: Изд-во Михайлова В.А., 2004. 496 с.
6. Киселев А.Г. Теория и практика массовой информации: общество – СМИ – власть: учебник. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2010. 431 с.

7. Корконосенко С.Г. Основы журналистики: учебник для студентов вузов, обучающихся по направлению и специальности «Журналистика». М.: Аспект Пресс, 2004. 285 с.
8. Коханова Л.А., Калмыков А.А. Основы теории журналистики: учеб. пособие. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2009. 535 с. URL: http://www.knigafund.ru/books/116269
9. Корконосенко С.Г. Теория журналистики: моделирование и применение: учеб. пособие. М.: Логос, 2010. 242 с. URL: http://www.knigafund.ru/books/7831.
10. Лазутина Г.В. Основы творческой деятельности журналиста: учебник для студентов высших учебных заведений, обучающихся по специальности «Журналистика». 2-е изд., перераб. и доп. М.: Аспект Пресс, 2007. 239 с.

**Интернет-чыганаклар**

Татарская электронная библиотека. URL: http://kitap.net.ru/
Интернет газета. TATAR ZAMANI. URL: http://www.tatartime.com/
Матбугат.ру. URL: http://matbugat.ru/

## «ЖУРНАЛИСТ ЭШЧӘНЛЕГЕ НИГЕЗЛӘРЕ (ЖАНРЛАР)» дисциплинасы

1. Журналистикада «жанр» төшенчәсе. Жанр төркемнәре.
2. Хисап жанрының үзенчәлекләре.
3. Хәбәри төркемгә керүче жанрлар. Аларның уртак сыйфатлары.
4. Нәрсә ул «һөнәр алыштыру» алымы?
5. Репортер өчен мәгълүмат чыганаклары.
6. Интервью. Аның төрләре.
7. Хәбәр. Аның төрләре, төзелеш үзенчәлекләре.
8. Конкретлыкка һәм сурәтлелеккә ирешү чаралары.
9. Репортаж. Аны ничек язарга?
10. Жанрларның тарихилыгы.
11. Хәбәри жанрдагы язмаларның уртак тел-стиль үзенчәлекләре.
12. Рус журналистикасында репортаж осталары.
13. Хәбәри язмалар остасы буларак Габдулла Тукай.
14. Интервьюның эчтәлегенә йогынты ясаучы факторлар.
15. Фатих Әмирхан иҗатында хәбәри жанрлар.
16. Хәбәри текстларда баш исеме һәм башлам төрләре.
17. Репортажның тел-стиль үзенчәлекләре.
18. Татар журналистикасында хисап жанрының осталары.
19. Г.Сагал – интервью остасы.

- Татарские печатные календари: становление и развитие (вторая половина XIX – начало XX вв.) // Журналистская наука в Казанском университете: концепции диссертационного исследования / под общей ред. А.А.Роот. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. С. 548–560.
- Связь между календарями и газетами // Наука, технологии и коммуникации в современном обществе. Материалы республиканской научно-практической конференции (11-15 февраля 2008 года). Набережные Челны, 2008. С.233-234.

**2009 ел.**

- К вопросу о календаре как типе периодического издания // Журналистика в 2008 году: общественная повестка дня и коммуникативные практики СМИ: сборник материалов Всероссийской научно-практической конференции. М.: Факультет журналистики МГУ имени М.В.Ломоносова; Медиа Мир, 2009. С. 299–300.
- Роль татарских календарей военных лет в формировании патриотизма // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2009. Т. 151, кн. 5, ч. 2. С. 202–207.
- К вопросу о календаре как типе периодического издания (на примере календарей на татарском языке) // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2009. Т. 151, кн. 5, ч. 1. С. 110–117.

**2010 ел.**

- История России на страницах татарских календарей // Журналистика в 2009 году: общественная Трансформация СМИ в современном мире: сборник материалов Международной научно-практической конференции.

М.: Факультет журналистики МГУ имени М.В.Ломоносова, 2010. С. 366–367.

**2011 ел.**

- Тематические предпочтения татароязычных газет и журналов // Региональные СМИ: проблематика, тенденции развития: коллективная монография / науч. ред. С.К.Шайхитдинова. Казань: Казан. ун-т, 2011. С. 113–129.
- Советы и рекомендации на страницах татарских календарей // Татарская журналистика в XXI в. Векторы развития: сборник материалов научно-практической конференции, посвященной 75-летию со дня рождения Флорида Агзамова. Казань: Казан. ун-т, 2011. С. 74–79.
- Журналистика 021400 белгечлеге буенча дәүләт имтиханы: программа, бәяләүче чаралар, әзерләнү өчен материаллар. Казан: Казан ун-ты, 2011. 40 б.
- Журналистиканың хокукый нигезләре: уку ярдәмлеге. Казан: Казан ун-ты, 2011. 120 б.

**2012 ел.**

- Формирование и развитие жанров рекомендации и мини-совета в татарских календарях // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2012. №5. С. 79–82.
- Печатный календарь на татарском языке как средство коммуникации // Информационное поле современной России: практики и эффекты. материалы (международной научно-практической конференции, 18–20 октября 2012 г. / под ред. Р.П.Баканова: в 2-х т. Т.1. Казань, Казан. ун-т, 2012. С. 171–173.

**2013 ел.**

- Концептуальные основы исследования истории татарской журналистики // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. 2013. Том 155, Книга 6. С. 125–135. (В.З.Гарифуллин белән авторлыкта).

**2014 ел.**

- Журналистның һөнәри этикасы (программа, методик күрсәтмәләр, лекцияләр): укыту-методик кулланмасы. Казан: Казан ун-ты, 2014. 48 б.

## И.Ф. Фәттахов хезмәтләре

**2008 ел**

- Актуальные проблемы современной татарской стилистики // Информационное поле современной России: практики и эффекты:

материалы V Международной научно-практической конференции (16–18 октября 2008 г.) / под ред. В.З.Гарифуллина; сост. Р.П.Баканов. К.: Изд-во КГУ, 2008. С. 281–285.

- Фидаи җаннар иде алар (мәрсия) // Милләт. Заман. Шәхес: тарих фәннәре докторы Г.Л.Фәйзрахманов истәлегенә җыентык / җаваплы мөхәр. һәм төз. И.К.Заһидуллин. Казан: ТР ФАның Ш.Мәрҗәни исем. Тарих ин-ты, 2008. Б. 196–198.
- Эшләгән эше таулар кадәр... (Остазым Т.Н.Галиуллинның иҗат портреты) // Мәгърифәт. 2008. 19 июль.

**2009 ел.**

- М.Магдиев – публицист (1990–1995 гг.) // Тонус. 2009. № 17. С. 222–226.
- Халкыбызның рухый остазы (Ризаеддин Фәхреддин хакында) // Юлдаш («Дин вә йола» кушымтасы). 2009. апр.
- Освещение духовной жизни в светских и мусульманских СМИ Республики Татарстан // Исламоведческие исследования в современной России и СНГ: достижения, проблемы, перспективы**:** материалы I Международного научно-практического симпозиума (КГУ, 19–20 февраля 2009 г.): В 2-х т. Т. II / под ред. Б.М.Ягудина. Казан: «Intelpress+», 2009. С. 202–211.

**2010 ел.**

- Туган тел сакчысы иде (Остазым хакында мәрсия) // Хаков укулары – 2010. Студент һәм аспирантларның Казан дәүләт университеты атказанган профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаков истәлегенә багышланган төбәк фәнни-гамәли конференциясе материаллары / төз.: Ф.Ш.Нуриева, Х.Х.Кузьмина, Г.Ф.Гайнуллина, Л.Н.Закирова. Казан: Ихлас, 2010. Б. 22–24.
- Тагын орфографиябез турында // Хаков укулары – 2010. Студент һәм аспирантларның Казан дәүләт университеты атказанган профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаков истәлегенә багышланган төбәк фәнни-гамәли конференциясе материаллары / төз.: Ф.Ш.Нуриева, Х.Х.Кузьмина, Г.Ф.Гайнуллина, Л.Н.Закирова. Казан: Ихлас, 2010. Б. 89–92. (А.Ш.Шәймәрданов белән авторлыкта).

**2011 ел.**

- Әдәбият теориясе нигезләре: уку ярдәмлеге. Казан: К(И)ФУ нәшр., 2011. 208 б.
- Язучы-публицист осталыгы серләре: уку ярдәмлеге. Казан: К(И)ФУ нәшр., 2011. 64 б.

- Р.Харис иҗатында милләтара багланышлар // Ренат Харис һәм татар шигърияте: Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Хариска (Ренат Мәгъсүм улы Харисовка) 70 яшь тулуга багышланган бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 2011 ел, 21 апрель) / фән. ред. Т.Н.Галиуллин, төз. Ф.Ф.Хәсәнова. Казан: «Идел Пресс», 2011. Б. 113–118.
- Безнең авылның энциклопедиясе (М.Мәһдиевнең иҗат портретына эскизлар) // Классик филология һәм КФУның татар филологиясе һәм тарихы факультеты галимнәре: төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 2011 ел, 18 март) / фән. мөхәр. Х.Й.Миңнегулов, төз.-мөхәр. Т.Ш.Гыйлаҗев. Казан: Казан ун-ты, 2012. Б. 66–80.
- И.Ф. Гази Кашшаф публицистикасында Муса Җәлил образы // Татар журналистикасы XXI гасырда: үсеш юллары. Флорид Әгъзамовның тууына 75 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 2011 ел, 11 февраль) / ред. В.З.Гарифуллин, төз. Р.М.Галиева. Казан: Казан ун-ты, 2011. Б. 84–86.

**2012 ел.**

- Публикации о Габдулле Тукае на страницах журнала «Совет әдәбияты» («Советская литература»): обзор номеров за 1950–1957 гг. // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы IX Международной научно-практической конференции, 18–20 октября 2012 г. / под ред. Р.П.Баканова: в 2-х т. Т. II. Казан: Казан. ун-т, 2012. С. 113–120.
- Мөхәммәт Мәһдиев дөньясына бер караш // «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният: журналның 90 еллык юбилеена багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары (2012 ел, 17 май) / төз.-мөхәр. Ә.М.Закирҗанов. К., 2012. Б. 103–105.

**2013 ел.**

- Равил Фәйзуллин – публицист // Равил Фәйзуллин: шәхес, иҗат, заман: Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга (Равил Габдрахман улы Фәйзуллинга) 70 яшь тулуга багышланган бөтенроссия фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 2013 елның 17–18 октябре) / төз. Ә.М.Закирҗанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. Б. 292–300.
- Муса Джалиль в публицистике Гази Кашшафа // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы X Международной научно-практической конференции (17–19 октября 2013 г.) / под ред. Р.П.Баканова. Казан: Казан. ун-т, 2013. С. 113–117.

- Роль Гази Кашшафа в пропаганде творчества Мусы Джалиля // Фундаментальные и прикладные науки сегодня: материалы II международной научно-практической конференции (19–20 декабря 2013 г., Москва). М., 2013. В 2–х т. Т. I. С. 200–204.

**2014 ел.**

- Гази Кашшаф чорындагы «Совет әдәбияты» журналында публицистика // Современное коммуникативное пространство журналистской науки, практики и образования: контуры и реальность новых медиа. Выпуск 5: сборник научных статей / под ред. В.З.Гарифуллина, Е.С.Дорощук. Казань: Казан. ун-т, 2014. С.113–129.
- Гөберчәгем, Кесмәс буйларым... // Шәһри Казан. 2014. 28 март.
- Мәһдиев авылы гөрләп яши // Акчарлак. 2014. 30 апр.
- Нәфис сүз остасы // Кызыл таң. 2014. 17 апр.
- И туган тел... // Мәдәни җомга. 2014. 25 апр.

## Р.М. Галиева хезмәтләре

**2009 ел.**

- 90-летие газеты «Ватаным Татарстан». / под ред. М.М.Ахлиуллина. Казань: Идел Пресс, 2009. 224 с.

**2010 ел.**

- Татарские сатирические журналы начала XX века на татарском языке. Казань: Казан. ун-т. 2010. 181 с.
- Журналист-сатирик осталыгы: учеб. программа. Казань: Казанский (Приволжский) федеральный университет, 2010. 12 с.
- Журналистның иҗади эшчәнлеге нигезләре. Әдәби публицистика: сатирик жанрлар: учеб. программа. Казань: Казанский (Приволжский) федеральный университет, 2010. 12 с.
- Мастер-класс: журналист тикшерүе: учеб. программа Казань: Казанский (Приволжский) федеральный университет, 2010. 9 с.

**2011 ел.**

- Флорид Әгъзамов – фельетончы // Татарская журналистика в XXI веке: векторы развития: сборник материалов научно-практической конференции, посв. 75-лет. годовщине со дня рожд. Флорида Агзамова. Казань: Казанский (Приволжский) федеральный университет, 2011. С. 79–84.
- Зрелый журналист, опытный мастер пера... // Флорид Әгъзамов: осталар остазы. Казань: Казанский (Приволжский) федеральный университет, 2011. С. 35–37

- Журналистика требует самоотдачи // Тенденции развития современной российской журналистики: сборник статей. Москва: изд-во МГУ, 2011. С. 17–21.

**2012 ел.**

- Язма фәнни эшләр: журналистика бүлегендә укучы студентлар өчен методик кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2012. 52 с.
- Язмаларда – язмышлар // Сборник публицистических материалов на татарском языке. Казань: Институт истории АН РТ, 2012. 203 с.
- Мөхлисә Бубый кем ул? // Женщины-просветители XIX–XX века: сборник статей. Казань: Институт истории АН РТ, 2012. С. 27–29.

**2013 ел.**

- Языковые особенности сатирических материалов журнала «Чаян» // Филология и культура. ВАК. Казань: Изд-во «Ихлас», 2013. С. 21–23.

## Л.Р. Сабирова хезмәтләре

**2008 ел.**

- Татарские СМИ: проблема вхождения в рынок // Общественная повестка дня и коммуникативные практики СМИ: Всероссийская научно-практическая конференция «Журналистика 2008»: сб. ст. М.: МГУ им. М.В.Ломоносова, 2008. С. 321–322.

**2009 ел.**

- Речевые особенности жанра интервью в татарском языке // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2009. Т 151, кн. 5, ч. 1. С. 99–109.
- Что изучает медиалингвистика? // Тонус. 2009. №17. С. 213–217.
- Особенности татарской речевой системы: различие свойств языка и речи // Тонус. 2009. №17. С. 218–221.
- Культура в зеркале современных СМИ Татарстана // Мультикультурная современность: Урал–Россия–Мир: материалы XII Международной научно-практической конференции. Екатеринбург, 2009. С. 306–309.
- Интервью – сөйләм баету чарасы // Мәдәни җомга. 2009. 27 март. С. 12.
- Влияние «медийного языка» на развитие общенационального языка // Проблемы массовой коммуникации: материалы XX межвузовской научно-практической конференции. Воронеж: ВГУ, 2009. С. 156–159.

**2010 ел.**

- Речевые особенности жанра интервью на татарском языке // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы Седьмой Международной научно–практической конференции 21–23 октября 2010 г. / под. Ред. В.З.Гарифуллина / вып. ред. Р.П.Баканов. Казань: Казан. ун-т., 2010. С. 254–259.
- Мотивационные основы татарской речи в интервью // Казанская наука. Казань: Изд-во Казанский Издательский Дом, 2010. № 9. Вып. 2. С. 73–77.

**2011 ел.**

- Речевые особенности жанра интервью на татарском языке. Казань: Казан. ун-т. 2011. 164 с.
- Иҗтимагый тәрҗемә теориясе һәм практикасы: учеб. программа. Казань: Казанский университет, 2011. 16 с.
- Татар рекламы һәм матбугат: учеб. программа. Казань: Казанский университет, 2011. 20 с.
- Мастер-класс: региональ матбугатта интервью жанры: учеб. программа. Казань: Казанский университет, 2011. 16 с.
- Современное состояние национальной рекламы в республике Татарстан // 20 лет постсоветской России: кризисные явления и механизмы модернизации: материалы XIV Всероссийской научно-практической конференции Гуманитарного университете, 19–20 апреля 2011 года: доклады / редкол.: Л.А.Закс и др.: в 2 т. Екатеринбург: Гуманитарный ун-т, 2011. Т.2. С. 442–445.
- Татарский язык в условиях двуязычия // Актуальные вопросы теории и практики филологических исследований: материалы международной научно-практической конференции 25–26 марта 2011 года. Пенза – Москва – Решт: Научно-издательский центр «Социосфера», 2011. С. 239–242.
- Современное состояние национальной рекламы в республике Татарстан // Российские СМИ и журналистика в новой реальности: материалы Международной науч.-практ. конф., посвященной 75-летию журналистского образования на Урале (Екатеринбург, 14–15 апреля, 2011г.) / факультет журналистики Урал. гос. ун-та [Электронный ресурс]. Электрон. дан. Екатеринбург, 2011. 1 электрон. опт. диск (CD–ROM). С. 302–305.
- Трансформация системы жанров в татарской журналистике // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы VIII Международной научно-практической конференции Казань, 20–22 октября 2011 г. / под. ред. В.З.Гарифуллина, Р.П.Баканова. Казань: Казан. ун-т., 2011. С. 357–361.

- Сөйләм теле буларак хәбәри жанрлар // Татар журналистикасы XXI гасырда: үсеш юллары: Флорид Әгъзамов тууына 75 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан. 11 февраль, 2011 ел. / ред. В.З.Гарифуллин; төз. Р.М.Галиева. Казан: Казан ун-ты, 2011. Б. 168–172.
- Умрут ли газеты? // Мультимедийная журналистика Евразии – 2011: традиции и инновации Востока и Запада: сборник научных статей и материалов V Международной научно-практической конференции, Казань, 15–16 дек. 2011г / науч. ред. проф. Е.С.Дорощук. Казань: Казан. ун-т, 2011. С. 205–209.

**2012 ел.**

- Язма фәнни эшләр: журналистика бүлегендә укучы студентлар өчен методик кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2012. 52 с.
- Татарский язык в условиях глобализации // ПОКОЛЕНИЕ БУДУЩЕГО – 2012: взгляд молодых ученых: Международная молодежная научная конференция: г. Курск, 14–20 ноября 2012 г. / отв. редактор Горохов А.А. Т.2. С.186–189.
- Жанровая характеристика современной прессы Татарстана // Информационное поле современной России: практики и эффекты: материалы IX Международной научно-практической конференции, 18–20 октября 2012 г. / под. ред. Р.П. Баканова: в 2-х т. Т.1. Казань. ун-т, 2012. С. 384–387.
- Курс «Жанр интервью в региональной прессе» как мастер-класс для будущих журналистов // Мультимедийная журналистика Евразии –2012 – Евразия молодая: международные медиапроекты, глобальные Сети и информационные тренды Востока и Запада. Казань, 12–14 дек. 2012: материалы VI Международной научно-практической конференции. Казань: Казан. ун-т, С.137–142.

**2013 ел.**

- Мотивационные основы татарской речи в жанре интервью. Казанская наука. №7. 2013. Казань: Изд-во Казанский Издательский Дом, 2013. С.172–175.
- Жанр буларак интервью («Ватаным Татарстан» газетасы мисалында) // Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар: гомуми урта, махсус һәм югары белем бирү йортларында укучыларның IV Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары (Казан, 21 нче февраль, 2013). Казан: КФУ, 2013. Б. 342–344. (Л.Р.Фатыйхова белән авторлыкта).

- Особенности татарской информирующей речи в жанре интервью // Информационное поле современной России: практика и эффекты: материалы Десятой Международной научно-практической конференции, 17–19 октября 2013г. / науч. ред. проф. Е.С.Дорощук. Казань: Казан.ун-т, 2013. С. 319–321.
- Күтеп алынган дәреслек // Мәдәни җомга. 2013. 22 апрель. С. 13.

**2014 ел.**

- Vasil Zagitovich Garifullin, Lyailya Rashitovna Sabirova. Place of Internet Resources in the System of Islamic Mass Media in Russia // World Applied Sciences Journal 30 (12): 1808–1810, 2014 ISSN 1818–4952 IDOSI Publications, 2014 DOI: 10.5829/idosi.wasj.2014.30.12.14270 (В.З.Гарифуллин белән авторлыкта).
- Татар теленең киләчәге һәм матбугат // Современное коммуникативное пространство журналистской науки, практики и образования: контуры и реальность новых медиа. Выпуск 5: сборник научных статей / под ред. В.З.Гарифуллина, Е.С.Дорощук. Казань: Казан. ун-т, 2014. С. 109–112.
- Журналистлар әзерләү процессында тәрҗемә принципларына өйрәтүнең әһәмияте // Современное коммуникативное пространство журналистской науки, практики и образования: контуры и реальность новых медиа. Выпуск 5: сборник научных статей / под ред. В.З.Гарифуллина, Е.С.Дорощук. Казань: Казан. ун-т, 2014.С. 73–78.

## М.М. Сәфәров хезмәтләре

**2008 ел.**

- По случаю юбилея // Милли матбугат: хәзергесе һәм киләчәге: «Ватаным Татарстан» газетының 90 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан. 2008. 19 май. Казан: Идел Пресс. 2008. Б. 127–131.

**2011 ел.**

- Газеталарыбызның гомере озынмы? // Татар журналистикасы XXI гасырда. Үсеш юллары. Флорид Әгъзамовның тууына 75 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. Казан. 11 февр. 2011 ел. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2011. Б. 13–17.

**2013 ел.**

Һич онытасым юк…Казан: Идел Пресс. 2013. 351 б.

# РЕДАКЦИЯДӘ ИҖАТ КӨНЕ ҺӘМ ПРАКТИКА

Практика – Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтының журналистика кафедраларында укыту барышының аерылгысыз өлеше. Практик күнекмәләр алмаган кеше, гәрчә ул теоретик яктан югары әзерлекле булса да, чын белгеч була алмый. Шуңа күрә журналистика бүлегендә студентларның газета-журнал, телевидение һәм радио редакцияләрендә, мәгълүмат агентлыкларында, нәшриятларда, реклама оешмаларында, матбугат үзәкләрендә, интернет-басмаларда газеталарда практика үтүләренә зур игътибар бирелә.

Журналистика юнәлешенә йөз тоткан студентның безгә килгәнче үк шактый портфолиосы калынайган була. Институтка аяк басу белән студентлар практик күнекмәләр ала башлый. Беренчедән, күп кенә журналистика предметлары практик һәм лаборатор дәресләр белән тәэмин ителә. Андый дәресләрдә студентлар журналистика әсәрләрен әзерләү методикасы белән таныша, үзләре дә иҗат итә, язмаларын бергәләп тикшерә. Икенчедән, һәр курста һәр студентка атнага бер иҗат көне бирелә. Бу көнне булачак журналистлар төрле гаммәви мәгълүмат чараларында эшли, ягъни үзләре тәкъдим иткән яки редакция биргән темаларга әсәрләр яза, авторлар белән аралаша, материаллар тәрҗемә итә. Өченчедән, студентлар уку дәвамында җәйге айларда практика уза. Практика 4 ел эчендә 3 айга якын җыела.

Шулай итеп, студентларга өзлексез практика тәэмин ителә.

Практик һәм лаборатор дәресләр теоретик курслар кысаларында махсус план һәм методика буенча үткәрелә. Шунлыктан биредә практиканың бу төренә тукталып тормыйбыз. Сүз иҗат көннәрен һәм практикаларны ничек оештыру хакында барачак.

Иҗат көннәре һәм практикалар татар газета-журнал редакцияләрендә, радио-телевидение үзәкләрендә, мәгълүмат агентлыкларында, ведомство яки предприятиеләрнең матбугат хезмәтләрендә, нәшриятларда, реклама оешмаларында уза. Иҗат көннәре һәм практикалар түбәндәге гомуми максат һәм бурычларны күздә тота:

а) уку барышында алган теоретик белемнәрне гамәли үзләштерү, иҗат барышында ныгыту, журналистик әсәр язып бастыру яки эфирга чыгару, берничә материалны русчадан татарчага тәрҗемә итү;

б) практика үтә торган газета-журналның, радио яки телеүзәкнең, мәгълүмат агентлыгының, ведомство яки предприятиеләрнең матбугат хезмәтләренең тарихы, бүгенге төзелеше, эш юнәлешләре һәм үзенчәлекләре белән төптән танышу;

в) редакциянең хатлар, авторлар активы белән эшләү тәҗрибәсен өйрәнү; берничә автор материалын әзерләү, гаммәви чаралар (укучылар белән очрашулар, анкета уздыру һ.б.) үткәрүдә катнашу;

г) тәҗрибәле журналистларның иҗат остаханәсе белән танышу, аларның осталык серләренә төшенү;

д) секретариат эшендә катнашып, газета яки журналның берничә санын макетлау яисә радио-телевидение, мәгълүмат агентлыгының чыгарылышын әзерләүдә катнашу, коллективта эшне планлаштыру, фәнни оештыру үзенчәлекләрен өйрәнү, «летучкада» күзәтүче сыйфатында чыгыш ясау;

е) мәгълүмат хезмәте күрсәтелә торган төбәк тарихы белән кызыксыну, аның иҗтимагый, милли, социаль-демографик төзелешен, анда яшәүче төрле милләт вәкилләренең рухи хәзинәсен, традицияләрен, гореф-гадәтләрен өйрәнү;

ж) иҗат коллективының аудитория белән элемтә формаларын белергә тырышу, аның сорау-ихтыяҗларын өйрәнүдә катнашу.

Барлык практика төрләрендә студент программаны белергә, гаммәви мәгълүмат чаралары турындагы федераль законны, редакция уставын төгәл үтәргә, башкарыла торган эшнең нәтиҗәсе өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш. Иҗат көннәре һәм практикалар программасын үтәмәгән, канәгатьләнмәслек сыйфатлама яки начар билге алган студент уку барышында практикага яңадан җибәрелә яки университеттан чыгарыла.

Билгеле шартларга һәм редакцияләрнең йөкләвенә бәйле рәвештә, язылырга тиешле материалның жанрын икенче тиңдәш жанр белән алыштырырга мөмкин.

Практикант үз чыгышының яисә үзе оештырган материалның дөреслеге һәм авторларны, объектларны сайлау өчен тулысынча җавап бирә.

## «ИҖАТ КӨНЕ»Н
## ҺӘМ ПРАКТИКАЛАРНЫ ОЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ

Соңгы елларда «иҗат көне»н һәм практиканы оештыруның тотрыклы формалары барлыкка килде. Һәр эш кебек үк, иҗат та билгеле бер дәрәҗәдә оештыруга мохтаҗ.

Татар журналистикасы бүлеге студентларының «иҗат көне»н оештыру өчен татар журналистикасы кафедрасы җаваплы. Кафедра аның эчтәлеген, программасын, оештыру формаларын, вакытын билгели, контрольдә тота.

Кафедра укытучылар составыннан һәм редакция хезмәткәрләре арасыннан «иҗат көне»нең һәм практикаларның җитәкчеләрен билгели.

Алар һәр студентка иҗади ниятләрен яки редакция биремнәрен тормышка ашырырга ярдәм итә.

**«Иҗат көне»н оештыру**. Кафедра сентябрьнең беренче атнасында ук барлык курс студентларын, иҗади ниятләренә, махсуслашу юнәлешенә, журналистлар коллективларының ихтыяҗларына карап, газета-журнал, радио-телевидение, китап нәшрияты, мәгълүмат агентлыгы редакцияләренә, матбугат үзәкләренә, реклама оешмаларына беркетә. Студентлар җитәкчеләре белән бергәләп «иҗат көне»ндә эш итү кагыйдәләрен үзләштерәләр, консультация вакытларын беләләр, «иҗат көне»нең максаты, бурычлары, программасы белән танышалар.

Теләсә кайсы курс студенты «иҗат көне»н, кагыйдә буларак, әсәр өчен материал туплау, конкрет ситуацияне өйрәнү, җитәкчеләре белән очрашып киңәшләр алу, язманы җиренә җиткерү өчен файдалана. Һәрхәлдә, җитәкчеләр студентның «иҗат көне»ндә нинди конкрет мәсьәләләрне хәл кылуын белеп торырга тиеш. Әлбәттә, иҗатны атнага бер көн белән генә чикләргә ярамый. Ул һәрдаим дәвам иттерелергә тиеш. Әйтик, «иҗат көне»н материал җыю өчен файдалансаң, икенче, өченче һ.б. көннәрнең икенче яртысын әсәрне язуга багышларга мөмкин.

Җитәкчеләр һәр студентка шәхси план төзергә һәм планны тормышка ашырырга булышалар. Ниһаять, алар «иҗат көне»нең нәтиҗәләренә йомгак ясыйлар.

**Практиканы оештыру**. Студентлар уку елы барышында үзләштергән теоретик белемнәрен һәм практик-лаборатор дәресләрдә, «иҗат көне»ндә алган күнекмәләрен практика вакытында янә дә тирәнәйтәләр һәм конкретлаштыралар. Практикада студентлар редакция хезмәткәрләре башкара торган вазыйфаларны үтиләр һәм эшнең нәтиҗәләре өчен алар белән бер үк дәрәҗәдә җавап тоталар.

Студентларга ел башында ук кафедрадан җитәкчеләр билгеләнә. Алар кафедра планы нигезендә практикантларны редакцияләргә беркетәләр. Практиканың программасы, аны үтәү һәм йомгаклау үзенчәлекләре белән таныштыралар, студентларның иҗат ниятләре белән кызыксыналар, шул ниятләрне уңышлы итеп тормышка ашыру максатында киңәшләр бирәләр.

Практикантка, урынга барып җитү белән үк, редакциядән тәҗрибәле җитәкче билгеләнә. Җитәкче аңа программаны җиренә җиткереп үтәү максатында шәхси план төзергә булыша. Планда практикант чыгышларының темасы һәм жанры (1 курс студенты өчен жанр тәгаенләнми), автор язмасын, тәрҗемә материалы оештыру, командировка, редакциянең гаммәви һәм эчке эшендә катнашу формалары билгеләнә.

Редакциядәге практика җитәкчесе студентларга программаны үтәү өчен шартлар тудыра, көндәлек бирем билгели, аның үтәлешен тикшереп тора, редакция тәртипләрен үтәвен тәэмин итә, практика тәмамлангач, аларга сыйфатлама яза. Сыйфатламада программаның үтәлеше, студентларның эшкә, иҗатка мөнәсәбәте, редакция эшендә катнашу-катнашмавы турында мәгълүмат бирелә.

## «ИҖАТ КӨНЕ» ҺӘМ ПРАКТИКАЛАРНЫҢ ПРОГРАММАСЫ

Һәр студент «иҗат көне»ндә һәм практика вакытында кафедра тәкъдим иткән программаны үти. Сүз дә юк, студент аны арттырып үтәсә, бигрәк тә яхшы. Программада эшнең күләме генә күрсәтелә. Кафедра коллективын, беренче чиратта, башкарылган эш сыйфаты, студентның һәр биремгә иҗади якын килүе, мөстәкыйльлеге кызыксындыра. Шуңа күрә программага уңай якка үзгәрешләр кертү һич тә хилаф эш саналмый.

Һәр курста студент, кафедра куйган максатка, үтелгән теоретик материалга, махсуслашу юнәлешенә, гаммәви мәгълүмат чараларының ихтыяҗларына карап, мәгълүм күләмдә һәм сыйфатта эш башкара. Табигый ки, программаларда курска бәйләнешле рәвештә аерма бар. Шунлыктан, программаларны курслап бирү урынлы булыр.

### I КУРС

**«Иҗат көне» программасы**. Иҗат көннәрендә студент, редакция һәм ул мәгълүмат хезмәте күрсәтә торган төбәк, предприятие белән танышу белән бергә, журналистика әсәре иҗат итүнең барлык этапларын уза, ягъни тема сайларга, реаль ситуацияне тикшерергә, аны иҗтимагый әһәмиятле проблема белән бәйләргә, текст тудыру методикасына төшенергә өйрәнә.

Студент «иҗат көне»ндә кафедра укытучысы һәм редакция хезмәткәре җитәкчелегендә алдан килешенгән план буенча түбәндәгеләрне башкара:

1 нче семестрда үзе тәкъдим иткән яисә редакция йөкләгән темаларга 3 язма әзерләп бастыра;

1–2 хат редакцияли;

1–2 язманы ручадан татарчага тәрҗемә итә;

редакция коллективы эшчәнлегендә катнаша.

Практикант теләсә кайсы жанрда иҗат итә ала. Әмма тема актуаль, аның чишелеше үзенчәлекле, формасы камил булырга тиеш.

**2 нче семестрда** да биремнәр шундый ук. Ләкин бу семестрда инде студентлардан мөстәкыйльрәк булу, кызыклы темалар тәкьдим итү,

аларны тирәнрәк чишү сорала. Мәстәкыйль язмалары саны да кимендә 4 булырга тиеш.

Максатка ирешү өчен студент шәхси иҗади план төзи, киләчәктә шуңа нигезләнеп иҗат итә.

Студентның «иҗат көне»ндәге эше өзлексез контрольдә тотыла. Һәр семестрдан соң аттестация үткәрелә. Аттестация вакытында студент семестр барышындагы эше хакында хисап тота, шулай ук кафедрадан һәм редакциядән студент белән турыдан-туры эшләгән җитәкчеләр чыгыш ясый, язма характеристикалар укыла. Студентлар бер-берсенең иҗатын анализлап язган рецензияләре белән таныштыралар.

**Җәйге практика программасы**. Уку елы тәмамлангач, 1 курс студентлары танышу практикасына җибәрелә. Бу практика, кагыйдә буларак, район газетасы яки шәһәр һәм республика басмалары редакциясендә үтелә. Уку елы барышында радиода, телевидениедә, мәгълүмат агентлыгында, матбугат үзәгендә, нәшрияттә, реклама оешмасында эшләгәннәр практиканы шунда ук уза ала.

Практика срогы – 4 атна (июнь–июль ае). Студентлар әлеге практика дәвамында, беренче бүлекчәдә бәян ителгән гомуми бурычларны үтәү белән беррәттән, әсәр иҗат итүнең барлык баскычларын редакциядә даими эшләү шартларында узалар. Шәрехләбрәк әйткәндә, практикантлар әсәрнең темасын билгеләргә, конкрет ситуацияне анализлау өчен аралашу кагыйдәләрен кулланырга, идеяне ачыкларга, проблеманы күзалларга, дөрес нәтиҗәләр чыгарырга, әсәрнең композициясен корырга, кирәкле сурәтләү чараларын табарга өйрәнәләр.

Студентлар түбәндәгеләрне эшләргә тиеш:

5 язма бастырырга;
1–3 хат редакцияли;
русчадан татарчага 1–2 язма тәрҗемә итә;
1–2 фоторәсем бирә;
1 газета санын макетлаштыруда катнаша (версткада эшли).

Радио, телевидение редакцияләрендә, мәгълүмат агентлыкларында, нәшриятларда, реклама оешмаларында практика үтүчеләргә, фоторәсем һәм макетлаудан тыш, югарыда күрсәтелгән күләмдә иҗади эш башкару бурычы йөкләнә.

Бу юлы да язмаларның жанрлары тәгаенләнми. Аларның тематикасы да төрле булырга мөмкин. Тематика практикантның иҗади ниятләренә һәм редакцияләрнең ихтыяҗына бәйле. Материаллар икътисадкамы, сәясәткәме, мәдәнияткәме h.б. – кыскасы, кайсы гына тармакка карамасын, тирән эчтәлекле, камил формалы булырга тиеш.

## II-III- IV КУРСЛАР

**«Иҗат көне» программасы.** II-III-IV курс студентлары да сентябрьнең беренче атнасында ук, махсуслашу юнәлешенә карап, төрле массакүләм мәгълүмат чараларына беркетелә. Аларга да атнага 1 иҗат көне бирелә.

Ел барышында студентлар «иҗат көннәре»ндә хәбәри һәм аналитик жанрларда эшләү методикасын гамәли үзләштерәләр.

Газетада, мәгълүмат агентлыкларында эшләүчеләр түбәндәге эшләрне башкара:

- II курсның 1нче семестрында ике хәбәр, репортаж, интервью, хисап иҗат итә, ә 2нче семестрда хәбәри, аналитик әдәби-публицистик жанр төрләренең һәрберсеннән икешәр (барысы алты) әсәр язып бастыра;
- III-IV курсларда семестр саен хәбәри, аналитик әдәби-публицистик жанр төрләренең һәрберсеннән икешәр (барысы алты) әсәр язып бастыра;
- семестр саен 2–3 хат редакцияли;
- семестр саен 2–3 газета номерын планлаштыруда, макетлауда һәм чыгаруда катнаша.

Радиода эшләүчеләр:

- репортер магнитофон белән эшләргә, тасманы монтажларга өйрәнә, тасманы монтажлау һәм язу техникасын тулысынча үзләштерәләр; радиорепортаж, радиоочерк, радиокомпозиция язып эфирга тапшыралар;
- фонотека һәм тавыш цехы эше белән танышалар.
- 4–5 сюжет әзерли;
- 1–2 материал тәрҗемә итә;
- 2–3 автор материалын әзерли.

Телевидениедә эшләүчеләр:

- видеорепортаж, телеочерк әзерләп эфирга тапшыра;
- проблемалы публицистик тапшыру сценариен иҗат итәләр; видеоязма процессы белән таныша;
- 4–5 хроникаль сюжет әзерли;
- 1–2 автор чыгышын оештыра.

Реклама оешмаларында, матбугат үзәкләрендә һәм китап нәшриятларында эшләүчеләр өчен махсус программа төзелә.

**Җәйге практика программасы**. II һәм III курсларны тәмамлаганнан соң җитештерү практикалары оештырыла. Икенче һәм өченче практика, гадәттә, район һәм шәһәр газеталары редакцияләрендә, радио һәм

телевидение үзәкләрендә, мәгълүмат агентлыкларында, реклам оешмаларында үтә.

Практикаларның дәвамлылыгы – 4 атна. Бу практика вакытында студентлар, корреспондент вазифаларын башкарып, хәбәри һәм аналитик жанрларны даими эшләү шартларында гамәли үзләштерәләр. Алар түбәндәгеләрне үтиләр:

хәбәри, аналитик һәм әдәби-публицистик жанр төркемнәренең һәрберсенә караган икешәр (барысы алты) әсәр язып бастыра;

2–3 хат эшкәртә;

2–3 материал тәрҗемә итә;

1–2 газета номерын планлаштыруда, макетлауда һәм чыгаруда актив катнаша;

«летучка»да чыгыш ясый.

Радиода практика үтүчеләр:

4–5 сюжет әзерли;

радиопрограмма әзерләү процессы белән җентекләп таныша.

Телевидениедә үтүчеләр:

4–5 сюжет әзерлиләр;

телевизион программа әзерләү процессы белән төптән таныша.

**Диплом алды практикасы программасы.** IV курста беренче гадәттә февраль аенда оештырыла. Бу практиканы студент үзе теләгән гаммәви мәгълүмат чарасында уза. Практика университетны тәмамлап эшкә барачак редакциядә үтелсә, бигрәк тә яхшы.

Практика срогы – 2 атна.

Әлеге практика студентның һөнәри әзерлек дәрәҗәсен билгеләргә тиеш. Төп игътибар махсуслашуны тирәнтен үзләштерүгә юнәлдерелә. Махсуслашу тематика яисә жанрлар буенча тормышка ашырылырга мөмкин. Практика вакытында студент 4 әсәр иҗат итәргә, 2 хат эшкәртергә, 2 материал тәрҗемә итәргә бурычлы. Ул шулай ук секретариатта эшләп ала, материалларны планлаштыруда, төзәтүдә һәм дөньяга чыгаруда катнаша, «летучка» да күзәтүче булып чыгыш ясый.

## ИҖАТ ЙОМГАКЛАРЫН ТИКШЕРҮ

«Иҗат көн»нәренең нәтиҗәләрен тикшерү өчен һәр курста ике тапкыр аттестация үткәрелә. Кече аттестация – 1 нче семестр азагында, 20 декабрьгә кадәр, курс аттестациясе – 2 нче семестр ахырында, 1 июньгә кадәр.

Аттестацияләр махсус төзелгән комиссия утырышында уза. Комиссия составына кафедра укытучылары, редакция хезмәткәрләре кертелә. Аттестациядә группа студентлары катнаша.

Аттестация алдыннан студентлар язма хисап тапшыралар. Хисап түбәндәгеләрне эченә ала:
а) басылган яисә эфирга чыккан әсәрләр,
б) редакцияләнгән, басмага әзерләнгән хатлар, автор материаллары,
в) тәрҗемәләр (русча нөсхәсе белән),
г) хисап (газета, радио яисә телестудия, мәгълүмат агентлыгы, нәшрият, матбугат хезмәте, реклама оешмасы эшенең үзенчәлекләре турында фикерләр, иҗат эшенең юнәлешләре, уңыш-кыенлыклар, җитәкче журналистның сыйфатламасы),
д) җитәкче укытучы бәясе.

Комиссия әгъзалары студентларның хисабы белән кече һәм төп аттестация алдыннан җентекләп таныша. Материалларны группа студентлары да укый. Алар арасыннан бер рецензент та билгеләнә, тикшерү вакытында һәр студент хисап тота. Рецензент, чыгыш ясап, иптәшенең эшенә бәя бирә. Аннары фикер алышу башлана. Җитәкчеләр – кафедра укытучысы һәм редакция хезмәткәре комиссия әгъзаларын студентның иҗат нәтиҗәләре белән таныштыра. Комиссия рәисе тикшерүгә йомгак ясый. Ахырдан студент эшенә бәя чыгарыла.

Тикшерү бүтән сценарий буенча да уздырылырга мөмкин.

Уку елы башлану белән үк практикант түбәндәге материалларны тапшыра:
– практика йомгаклары турында хисап;
– студентның басылган яки эфирга чыгарылган үз материаллары, оештырган һәм тәрҗемә иткән язмаларының нөсхәсе;
– студент башкарган һәм шул макетлар буенча чыгарылган газета саннары;
– практикант материалларының нәтиҗәлелеген раслаучы материаллар (рәсми җаваплар, укучы, тыңлаучы, тамашачы хатлары);
– студентның эшенә редакция биргән сыйфатлама;
– практикант көндәлеге.

Практиканы телевидение һәм радио студияләрендә, реклама оешмаларында үткән студентлар барлык материалларның текстларын (үзләренекен һәм авторларныкын), сценарийларын, шулай ук аудио- һәм видеоязмаларны тапшырырга тиеш.

Хисапның якынча схемасы түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

Практиканы кайда үттең? (газета, радио яки телестудиянең, мәгълүмат агентлыгының, матбугат хезмәтенең, реклама оешмасының исеме оештыручысы, җитәкчесенең исем-фамилиясе, редакциянең төзелеше, эш үзенчәлекләре һ.б.)

Кайсы бүлектә эшләдең, практикага кем җитәкчелек итте?

Практика дәверендә нинди темалар, юнәлешләр өстендә эшләдең, нинди проблемалар күтәрдең, материал оештыру өчен кайларда булдың, кемнәр белән аралаштың, ничек итеп мәгълүмат тупладың? Шул уңайдан килеп чыккан кыенлыклар нидән гыйбарәт?

Язма басылып чыккач яки тапшыру эфирда яңгырагач, күрсәтелгәч, ул укучылар, тыңлаучылар, тамашачылар тарафыннан ничек кабул ителде? Резонанс булдымы, әллә битарафлык күрсәтелдеме? Материалның нәтиҗәлелеге турында сөйләргә мөмкинме? Редакция хезмәткәрләре бу материалны ничек бәяләде?

Кайсы язмаларыңны, тапшыруларыңны иң уңышлылары яки иң уңышсызлары дип санныйсың? Ни өчен? Уңышсызларын ничегрәк итеп эшләргә кирәк булган?

Практика башында нинди максат һәм бурычлар билгеләнгән булып, шуларның кайсылары ни дәрәҗәдә үтәлгән? Үтәлмәгәннәренең тормышка ашмавы нинди объектив яки субъектив сәбәпләргә бәйле?

Киләсе елда практика үтәчәк төркемдәшләреңә, түбәнрәк курс студентларына киңәшләрең, практика оештыручыларга, редакциядән һәм кафедрадан билгеләнә торган җитәкчеләргә эшлекле тәкъдимнәрең нинди?

Практика нәтиҗәләрен тикшерү өчен һәр курста уку елының 1 семестрында махсус очрашу вакыты билгеләнә. Иң элек практика белән кафедрадан җитәкчелек итүче укытучы студентларның эшләре белән җентекләп танышып чыга, аларны студентлар да укый. Студентлар арасыннан һәрберсенә рецензент билгеләнә. Студентлар кафедра билгеләнгән җитәкче белән җәйге практикада башкарылган эшләргә анализ ясыйлар, хисап тоталар, рецензентларның фикерләрен тыңлыйлар. Ахырдан җитәкче бәя куя.

Практика өчен бәя куйганда, студентларның тикшерүдә катнашулары, рецензияләре, редакция биргән сыйфатламалары да исәпкә алына.

Барлык курсларда практикага йомгак ясалгач, Институтта махсус конференция үткәрелә. Анда студентлар, практика җитәкчеләре, журналистлар катнаша. Практиканы оештырудагы уңай яклар һәм кимчелекләр анализлана. Соңгыларын бетерү, гомумән, иҗат эшен камилләштерү юллары билгеләнә.

**«Редакциядә иҗат көненә» бәяләмә үрнәге**

**Көндезге бүлек студенты Диләрә Батыршинаның «Ватаным Татарстан» газетасында үткән иҗат практикасына бәяләмә**

Беренче курс студенты буларак, Диләрә тырыш, үз-үзенә таләпчән студент буларак истә калды. Киләчәктә бу сыйфатларын тагын да камилләштерүен теләп калам. Студент нинди эш башкарганын белеп башкара, бу да булачак журналист өчен мөһим сыйфатларның берсе.

Газетада шактый үзенчәлекле язмалары урын алды. «Ватаным Татарстан» газетасы белән беррәттән башка матбугат чарасы белән дә язышa алган. Моның, әлбәттә, уңай һәм тискәре яклары бар. Бердән, бер матбугатны өйрәнү мөмкинлеге аз кала, икенчедән, студент тарафыннан таркаулык барлыкка килә. Бу язмаларның санына да, сыйфатына да йогынты ясамый калмый. «Мин сайлаучы булдым» («Әтнә таңы»), «Апамның бирнәсе булдым», «Кояш кемне шелтәли» («Ватаным Татарстан»), «Швеция дә үзебезчә сөйләшә» («Мәдәни Җомга»), «Яшьнәгәндәй аяз күктә яшен» («Мәгърифәт») язмаларын билгеләп китәргә була.

Диләрәнең, Сибгат Хәкимнең якташы буларак, бу шәхескә кагылышлы язмалар сериясе дә үзенчәлекле. «Яшәргә риза мин монда әйләнеп бер туфракка», «Сибгат Хәким Күлле Кименеке! Ул безнеке!» язмалары шактый кызыклы. Журналистика тарихында билгеле бер шәхесне өйрәнеп, аның иҗатын күтәреп яшәгән публицистларыбыз шактый булды. Бәлки киләчәктә Д.Батыршина бу теманы тагы да киңрәк итеп дәвам итәр. Монда уйланырга җирлек бар.

Тәрҗемә һәм хатлар эшкәртүгә килгәндә, алар студент тарафыннан шактый башкарылды. Шул ук вакытта мин аны игътибарлырак булырга чакырам. Укучы алдында җаваплылык дигән төшенчәне онытмаска да кирәк.

Гомумән алганда, бу эшләр игътибарга лаеклы. Киләчәктә дә уңышлар теләп калам.

Ватаным Татарстан» газетасы
журналисты, филология
фәннәре кандидаты Р.М.Галиева
20.12.11.

## Иҗади портфолио материалларына бәяләмә үрнәге

### Алсу Хәнҗәрованың 2009–2014 елларда иҗат иткән практика материалларына бәяләмә

Студентның иҗат практикасы аның киләчәк тормышын, эш урынын күзалларга ярдәм итә, журналистика өлкәсендә эшчәнлегенә нигез булып тора. Алсу Хәнҗәрованың иҗади досьесы белән танышканнан соң бары тик уңай фикерләр генә кала. Автор биш ел дәвамында язмаларын район һәм республика матбугатында бастырып килә. «Шәһри Казан», «Безнең гәҗит» кебек матбугат чаралары белән беррәттән ул туган җире Чүпрәле районы газетасы булган «Туган як» белән дә элемтәсен өзми. Һәрвакыт аралашып яши. Шуңадыр аның язмалары берничә төрле теманы үз эченә ала. Алсуны күбрәк хокук өлкәсендәге мәсьәләләр кызыксындыра. Кеше тормышына куркыныч янаган мәсьәләләргә дә алына, җәмгыять проблемаларын чишәргә омтыла. Гаилә һәм социаль темага кагылышлы язмаларын автор төрле жанрлар аша укучыга җиткерә. «Яшенле яңгыр», «Милициям мине яклыймы?», «Язмышларны кем язар», «Яшьлек ялгышлары...», «Кемдер алдый, кемдер алдана», «Бүре баласы» язмаларында авторның аналитик фикерләве дә чагыла. Автор укучыга җиткерәсе фикерен төрле мисаллар аша дәлилли. Бер үк вакытта район газетасында даими язмалар әзерләү үзен сиздерә, авторның иҗади йөзе югалып та кала кебек. Газетаның күп еллар дәвамында калыплашкан стиле язмаларга да тәэсир итә. Шул ук вакытта язмаларның теле гади, укылышлы. Авторга үз йөзен һәм үз стилен булдыру өчен тагын да тырышырга кирәк. Алсу киләчәктә дә үзенең башлаган темаларын дәвам итсен иде.

Шунысы куанычлы, Алсу соңгы иҗат практикаларын ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы карамагында эшләп килүче Аграр яшьләр берлегендә үтә, биредә ул матбугат сәркатибе вазыйфасын башкара. Журналистка, язмалар гына әзерләп калмыйча, башка матбугат чаралары белән хезмәттәшлек тә итәргә туры килә. Сайтлар өчен дә язмалар әзерли ул.

Гомумән, Алсу Хәнҗәрова мәгълүматка бай иҗади досье әзерләгән, биш ел дәвамында уңышлы һәм намуслы эш башкарып чыккан. Аңа уңышлар телисе килә. Әлеге иҗат тупланмасын бик яхшы бәягә лаек дип табам.

Рәсимә Галиева, филология фәннәре кандидаты.

# ӘДӘБИЯТ

1. Галиева Р.М., Сабирова Л.Р. Язма фәнни эшләр: журналистика бүлегендә укучы студентлар өчен методик кулланма. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2012. 48 б.
2. ГОСТ 7.1–2003. Библиографическая запись. Библиографическое описание. Общие требования и правила составления // Библиография. 2004. № 3. С. 45–72; № 4. С. 41– 64.
3. Дорощук Е.С. Методические указания по выполнению выпускной квалификационной работы по журналитике: учеб.-методическое пособие. Казань: Казан.гос. ун-т, 2009. 44 с.
4. Журналистика 021400 белгечлеге буенча дәүләт имтиханы: программа, бәяләүче чаралар, әзерләнү өчен материаллар / төз. Р.Л.Зайни. Казан: Казан.ун-ты, 2011. 40 б.
5. Журналистика бүлегендә язма фәнни эшләр. Дәүләт имтиханы: методик кулланма / төзүче В.З.Гарифуллин. Казан: КДУ, 2007. 16 б.
6. Курсовая работа: методическое пособие по выполнению (подготовке) и защите для студентов отделений факультетов журналистики / науч. ред. М.В.Симкачева. Казань: Казан. гос. ун-т, 2009. 64 с.
7. Научно-исследовательская работа студентов: учеб.-методическое пособие / под ред. Д.В.Туманова. Казань: Изд-во Казан. гос. ун-та, 2007. 100 с.

# ИНТЕРНЕТ-ЧЫГАНАКЛАР

1. ГОСТ Р 7.0.5. 2008. URL: http://protect.gost.ru/v.aspx?control=8&baseC=-1&page=0&month=-1&year=-1&search=&RegNum=1&DocOnPageCount=15&id=165614&pageK=466BEF73-A91A-4347-AD85-14FA584A6CCC
2. Екатерина Антипова Е. Как писать курсовую – практические советы. URL: http://www.studroom.ru/view_post.php?id=4
4. План и структура дипломной работы, как написать диплом. URL: http://www.vipstudent.ru/index.php?q=data&r=1236076602
5. Умберто Эко. Как написать дипломную работу. URL: http://www.234555.ru/publ/2–1–0–337
6. Что такое курсовая работа? URL: http://ist–slavbalkan.narod.ru/study/kursov–pravila.htm
7. Оформление научного аппарата курсовой и дипломной работы. URL:. http://kpfu.ru/portal/docs/F1876319844/kdr.pdf